Президент туган авыл

Актаныш районы Әнәк авылында 102 хуҗалык исәпләнә. Авыл мул, тату яши. Биек манаралары белән әллә кайдан ук күренеп торган мәчеттән ерак түгел Шәймиевләр нигезе урнашкан. Ул 2004 елдан Актанышның «Туган як» музее карамагында йорт-музей буларак эшли, Минтимер Шәймиевнең әтисе Шәрип ага исемен йөртә.

10 БИТ

«Иң зур шатлык – торыр урының булу»

Тузган торак программасының үтәлеше белән танышырга 2000 елда Казанга ул чакта Россия Президенты вазифаларын башкаручы Владимир Путин да килгән булган. Минтимер Шәймиев белән алар тузган торакта яшәүче Хәзирә апа белән Шәйхулла абый гаиләсендә булганнар. Без бу гаиләне эзләп таптык. Инде 75 яшенә җитсә дә, истәлекле вакыйганы яхшы хәтерли Шәйхулла абый Шәрифуллин.

6 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 19.01.2017 | № 4 (5766) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БЕЗ БЕЛГӘН ҺӘМ БЕЛМӘГӘН ШӘЙМИЕВ

Татарстанның Беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә – 80 яшь

Шамил Абдюшев фотосы

4-13 БИТЛӘР

РЕСПУБЛИКАДА

БӨГЕЛМӘ

Бөгелмә шәһәрендәге Үзәк мәчет ачылганга быел – 25 ел. Шул уңайдан, Бөгелмә районы мөхтәсибәте Милади буенча 2017 елга стена календарьлары нәшер иткән. Әлеге календарьлар биш мең тираж белән бастырылып, халыкка бушлай таратылган.

ӘЛМӘТ

Әлмәттә рәссам Марс Минаҗев менә инде берничә ел рәттән ишегалдына кардан төрле сыннар ясап, райондашларын сөендерә. Быел исә кардан ясалган дүрт-биш метрлы сыннары аеруча истә калырлык булды. Крокодилның озын яшел койрыгыннан балалар рәхәтләнеп чана шуа.

ЧИРМЕШӘН

Чирмешәндәге картлар һәм инвалидлар интернат йортында яшәүче 81 яшьлек Нәдирә Җәләлованы күптәнге танышы эзләп тапкан. Әби Казанда яшәүче 33 яшьлек Соня белән картлар йортында танышкан булган, аны оныгы дип тә йөрткән. Алар хатлар алышканнар, ә әбине башка картлар йортына күчергәч, элемтә өзелгән. Яңа ел алдыннан әбине Соня эзләп табып, аңа күчтәнәчләр җибәргән.

КУКМАРА

Кукмара районы үзәгендә 2017 метрга сузылган яңа чаңгы юлы ачылды. Бу вакыйганы кукмаралылар 40 ел көткән. Бу мәктәп укучылары, әти-әниләр, спорт осталарының да яраткан урынына әйләнер дип уйлыйлар. Биредә төрле чаралар уздырырга, ГТО нормалары тапшырырга да җыеналар.

ӘГЕРҖЕ

Быел беренче тапкыр Әгерҗе районында барлык балалар бакчаларын да бер үк вакытта ябачаклар. Июль ае дәвамында биналарда ремонт эшләре үткәрергә җыеналар. Баксаң, җәйге чорда сабыйларны бакчага йөртмәү тәҗрибәсе күрше Удмуртия республикасында күптән сынала, ди. Әгерҗедә исә кайбер ата-аналар бу хәбәрдән аптырашта калса, икенчеләре, балалар бакчасына түлисе булмаячак, дип сөенә икән.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Тәмәке урынына – конфет

Салым кодексына үзгәрешләр кертелгәннән соң, 1 гыйнвардан Россиядә ел саен тәмәке продукциясенә акциз ставкалары артып барачак. Нәтиҗәдә бу тәмәкенең кыйммәтләнүенә китерәчәк. Белгечләр фикеренчә, быел бер кап тәмәкенең бәясе уртача 20-35 сумга артырга мөмкин. Кальян, электрон сигарет кебек продукцияләргә дә акциз салына.

ncrim.ru

Бу хәбәрне кабул итеп тә өлгермәдек, тагын бер яңалык җиткерделәр: Россия сәламәтлек саклау министры Вероника Скворцова тәмәке тартучылар өчен проблеманы хәл итү өчен яңа концепция тәкъдим итә. Әлеге концепциянең тулы варианты халыкка тәкъдим ителмәде әле, шулай да кайбер өлешләре буенча интернетта бәхәсләр бара. Тәмәке составында булган төрле тәм бирә торган кушылмаларны тыю, сигарет кабына кешеләрне җәлеп итә торган мәгълүматлар урнаштыру да рөхсәт ителмәячәк. Сүз уңаеннан, Европа илләрендә бу күптән гамәлдә инде. Таләпләрнең кырыскраклары да бар: 2014 елдан соң туганнарга тәмәке сатмау, тартучылар өчен эш сәгатен арттыру, сигарет көйрәтүчеләргә экологик салым кертү һәм башкалар.

Тәмәке тартуны тыя торган закон Россиядә 2013 елдан бирле гамәлдә. Тиешсез урында тәмәке тартучыларга 500-3000 сумга кадәр штраф яный. Былтыр гына да, закон бозган өчен, 14 меңнән артык кешегә штраф салганнар.

Рамил ГАРИФУЛЛИН,
психолог, психотерапевт:

– Тәмәке тартучы ирекле баштан, үз теләге белән тартмый, бу беренче чиратта, җитди авыру – табакомания, ягъни тәмәкегә бәйлелек. Әгәр кешене тәмәке тартудан кискен туктатсаң, анда «кире кагу» синдромы башланырга, өянәге тотарга мөмкин. Мондый очракта баш авырту, сару кайнау күзәтелә. Тәмәке сатмау, тартучылар өчен эш сәгатен озайтуны мин кеше хокукларын чикләү дип кабул итәм. Тартучы кеше, өянәге башлангач, тәмәкегә үрелә. Хәлен шулай җиңеләйтә, аннары тагын эшкә тотына. Чөнки ул авыру. Тәмәке тартуны тыю турындагы тәкъдимнәрдә ниндидер яшерен мотивлар бар сыман. Тәмәке, кальян, электрон сигаретлар сату – бизнес. Бу өлкәдә дә көндәшлек җитәрлек. Тәмәкене үз тырышлыклары белән ташлаучылар да бар. Әгәр моны мөстәкыйль булдыра алмыйлар икән, психотерапевтларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Тәҗрибәмә таянып әйтә алам, тәмәкене ташлар өчен кемгәдер берничә сеанс та җитә.

Айрат САФИУЛЛИН,
механик:

– Мин дүртенче класстан бирле тәмәке тарттым. Сигаретны бармак арасына кыстыру да рәхәтлек бирә иде. Өйләнгәч, балаларым тугач, тәмәкене ташларга кирәклеген аңладым. Озак еллар эвкалипт үләне белән дәваландым. Хатыным бу хакта бер әбидән ишетеп кайткан булган. Файдасы тиде. Тартмагач, бер ел эчендә тазарып киттем. Сулыш алу да җиңеләйде. Бик нык тартасым килгәндә конфет суырам йә көнбагыш чиертәм. Улларыма начар үрнәк күрсәтергә ярамый, ничек тә тәмәкегә якынаймасыннар иде. Концепция генә тәмәкедән арындыра алмас анысы, бу – кешенең үзеннән, ихтыяр көченнән тора. Шулай да тәмәкенең зыяны турында тукып тору зыян итми.

Шәһәр кәефе

РӘИС САФИН,
пенсионер:

– Сөенечем зур: «Аллаһыга мәдхия» дигән шигырьләр китабым дөнья күрде. Диния нәзарәтенә рәхмәт! Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә дә 80 яшь тула. Аңа төрле кеше төрлечә бәя бирә инде. Олуг язучыбыз Әмирхан Еники «татарга руслардан аерылырга ярамый» дип язып калдырган. Минтимер Шәймиев тә «кайнар сәясәтчеләр» коткысына бирешмичә, тынычлык юлын сайлап дөрес эшләде.

АЛСУ ГОСМАНОВА,
режиссер:

– Казанда яши башлавыма – 7 ел, тумышым белән Азнакайдан. Киров районындагы Адмиралтия бистәсен туристлык үзәге сыйфатында төзекләндерә башлауларын түземсезләнеп көтәм. Тарихи биналар үзәк өлештә урнашкан. Шәһәр читендәге тарихи урыннарны җанландырсак, үзәктә транспорт тыгылышы да кимер иде. Велосипедта йөрергә бик яратам, шунлыктан җәйне сагынам. Мотоцикл сатып алырга хыялланам.

ФИРДӘВЕС ШАКИРҖАНОВА,
пенсионер:

– Элеккеге Ленин районында туып-үстем, Казанымнан аерылмадым. Күп еллар нәшриятта хезмәт куйдым. Һөнәри «чир» канга сеңгән, күрәсең, китаплар һәм газеталар укырга яратам. Чигү чигәргә яратмыйм. Театрга һәм концертларга йөрим. Балалар, оныклар, гомумән, яшьләр исән-сау булсыннар! Заманында әбиләребез: «Алла сакласын, сугышлар булмасын!» – дип әйтә торганнар иде. Хәзер менә без дөньяларның имин булуын телибез.

ГАЛИНА БОГДАНОВА,
пенсионер:

– Көн саен чаңгыда яки тимераякта шуып керәм. Физик күнегүләр организмга көч бирә, кәефне күтәрә. Чаңгыда шуа алмыйсың икән, ике таягына таянып булса да, саф һавада йөрергә кирәк. Хәрәкәттә – бәрәкәт, дигәннәр. Һаман да сукранып утыру, көнчелек хисе кешене бетерә. Казанда төрле милләт балалары бергә тәгәрәшеп уйнап үстек. Шушы дуслык, тынычлык мәңге саклансын. Кеше гомере бик кыска бит.



ЖЕНЯ СИДЕНОВ,
инструктор:

– Бурятия республикасыннан килгәнемә бер ел гына әле. Казан – гаҗәеп матур һәм хезмәт мөмкинлекләре зур булган шәһәр. Улан-Удэ моннан 4,5 мең километр ераклыкта, поездда дүрт көнгә якын кайтырга кирәк. Улан-Удэ шәһәрендә метро юк, шунлыктан Казан метросында йөрергә яратам. Станцияләр тагын да күбрәк төзелсен иде. Казанда чаңгы-тау комплексында эшлим. Спорт белән шөгыльләнәм, яшьләр компьютерга ябышып утырмасыннар иде.

Кискен тын юллары вируслы инфекциясе һәм грипп белән яңа ел алдыннан ук авырый башлаганнар иде. Бүген исә авыручылар саны 25 меңнән артып киткән. Аларның 80 проценты – балалар. 89 кешедә грипп очрагы теркәлгән. Авыру эпидемия бусагасыннан 62 процентка арткан. Былтыр эпидемия дүрт атна дәвам иткән булган, быел кайчанга кадәр сузылыр – вакыт күрсәтер. Әлегә беренче атнасы гына.

Эпидемия

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Авыручыларның күбесе Казан, Чаллы, Яшел Үзән шәһәрләрендә теркәлгән. Фаразлаганча, нәкъ менә Гонконг гриппы өстенлек итә. Хәер, Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, грипп нинди генә булмасын, «Техас»ныкымы, «дуңгыз»ныкымы, ул беренче чиратта, өзлегү китереп чыгару белән куркыныч.

– Грипп – ел саен кабатлана торган сезонлы авыру. Ул барыбер килә, аннан котылып булмый. Бары дөрес саклану һәм вакытында дәвалану чараларын күрергә кирәк, – ди Любовь Авдонина.

Казанда бу уңайдан, Татарстанның баш санитар табибы карары белән, мәгариф, медицина оешмаларында чикләүләр кертелгән. Әйтик, хастаханәләрдә авырулар янына якыннарын кертү, мәктәпләрдә укучыларны төрле чараларга йөртү вакытлыча туктатылып торачак. Шулай ук «маска» режимы да кертеләчәк. «Маска киюдән оялмаска кирәк», – ди Любовь Авдонина. Аны бары ике сәгать саен алыштырырга гына онытмаска киңәш ителә.

Былтыр дуңгыз гриппыннан өч кеше үлгән. «Быел мондый хәлләр булмас», – ди Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш инфекционисты Халит Хәертинов. Өстәвенә, бу юлы республика халкының 34 проценты прививка ясаткан булган. Бу, үз чиратында, авыручылар санын киметергә тиеш.

– Әгәр балалар бакчаларында, мәктәптә укучыларның 20 проценты авыру сәбәпле килмәгән икән, учреждение җитәкчесе, кискен тын юллары вируслы инфекциясен һәм грипп авыруын кисәтү максатында, укуларны җиде-ун көнгә туктатырга хаклы. Узган ел өч мәктәптә сигез класс шулай ябылып торган иде. Бу бик нәтиҗәле алым, – ди Любовь Авдонина.

Эльвира МОЗАФФАР.

Иммунитетны ныгыту мөһим, С витаминына бай ризыклар ашарга, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, дөрес тукланырга тырышыгыз.

Сеңгергән, төчкергән вакытта кулланылган салфеткаларны шунда ук чүплеккә ташларга кирәк. Авыруның вирусы предмет өслегендә 12 сәгатькә кадәр сакланырга сәләтле.

Телефон, каләм кебек еш кулланыла торган әйберләргә не гел сөртеп, инфекцияләрдән арындырып торырга кирәк.

Әгәр янәшәңдәгеләр авырыйлар икән, маска киеп йөрсәң ышанычлырак.

Тозлы су белән борынны юдыруны кагыйдәгә кертергә кирәк.

Онытмагыз: гриппны аяк өстендә үткәрергә ярамый.

Туйганчы йоклау, тиешенчә ял итү мөһим. Бүлмәне җилләтү, микробларны үтерә торган кварц лампаларын куллану да вирусларны киметә. Сәламәт булыйк!

Грипп һәм кискен тын юллары вируслы инфекциясе авырулары

ДӘВАЛАНУ

- Авыруның беренче билгеләре сизелүгә, 24 сәгать эчендә вируска каршы препаратлар, дарулар куллану файдалы.
- Табиб чакырырга кирәк. Мөстәкыйль дәваланырга ярамый. Гадәттә, югары температура авыруның иммунитетына бәйле рәвештә өч-җиде көн күзәтелергә мөмкин.
- Авырып китсәгез, өйдә калыгыз. Бигрәк тә авырган балаларны балалар бакчасына, мәктәпләргә җибәрергә ярамый.
- Күп итеп су эчәргә, С витаминына бай ризыклар ашарга киңәш ителә.
- Вакытында дәваланмаган грипп пневмония, борын кушылыгы ялкынсынуы, нерв белән бәйле авыруларга китерергә мөмкин.

БИЛГЕЛӘРЕ

- Баш, күзләр авырта
- Кинәт температура күтәрелә
- Аппетит югала
- Тән сызлый
- Томау, ютәл булырга мөмкин
- Борыннан кан китүе дә бар

Балалар бакчаларында – дежур төркемнәр

1 гыйнвардан балалар бакчасына түләү бәяләре уртача 230 сумга арткан иде. Яңа ел ата-аналар өчен тагын бер «күчтәнәч» әзерләгән. Казан Башкарма комитетының мәгариф идарәсе карары белән, 1 февральдән шәһәрдә 12 сәгать эшли торган төркемнәр бетерелә. Балалар бакчалары сәгать 7.30дан 18.00гә кадәр эшләячәк.

Эш сәгате кичке алтыга кадәр булган әти-әниләр өчен бу бер дә кулай түгел. Шуңа да балалар бакчаларында кизү тору төркемнәре булдырылачак. Дөрес, алар өчен аена 300 сум түләргә туры киләчәк. «Электрон белем бирү» порталында Казан шәһәре мәгариф идарәсенең җитәкчесе Илсур Һадиуллин бу мәсьәләгә аңлатма биргән. «Мәгариф оешмаларында оптимизация чаралары кысаларында, балалар бакчаларын 10,5 сәгатьлек эш режимына күчерү, иртәнге сәгать 7.00дән 7.30га һәм кич белән сәгать 18.00дән 19.00га кадәр эшли торган дежур группалар булдыру – балалар бакчасы өчен яхшы. Җыелган акча бинадагы көнкүреш шартларын яхшыртуга тотылачак. Бу, үз чиратында, педагогик кадрлар мәсьәләсен чишүдә дә ярдәм итәчәк». Балалар бакчаларында исә дежур төркемгә ихтыяҗ булган әти-әниләрдән имзалар җыя башладылар.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ТОП – 3

КЕРТЕМНӘРНЕ иминиятләштерү агентлыгы карары белән, бу атнада, ниһаять, «Татфондбанк» аша салым түләүчеләрне закон таләпләрен үтәгән дип санарга мөмкин. Бу хакта салым идарәсе комиссиясенә 20 миллион сумнан артык суммада 297 мөрәҗәгать кабул ителгән, дип хәбәр итте «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә Федераль салым хезмәтенең Татарстан идарәсе башлыгы урынбасары Андрей Никиташин. «Татфондбанк» аша салым түләүчеләрнең акчалары, банк белән бәйле вазгыять аркасында, тиешле органнарга барып җитмәгән иде. Нәтиҗәдә былтырның 30 декабрендә «Татфондбанк» аша салым түләгән эшмәкәрләрне бурычлылар рәтенә кертмәскә һәм аларга пенилар өстәмәскә дигән карарга килделәр. Шул вакытта салым акчалары бюджетка күчмәгән булып исәпләнде. Акчалар ике арада «эленеп торды».

РОССИЯНЕҢ хезмәт һәм социаль яклау министры Максим Топилин фаразлавынча, быел халыкның хезмәт хакы артырга тиеш. «2016 ел нәтиҗәләре буенча, чынлыкта да хезмәт хакы күтәрелер дип уйлыйбыз. Эшсезлек дәрәҗәсе дә артмас дип көтелә», – дигән ул «Российская газета»га биргән әңгәмәсендә. Бюджет өлкәсендәгеләрнең хезмәт хакы артуга Президентның указлары да тәэсир итми калмас, дип саный министр. Татарстанда исә былтырның беренче ярты еллыгында уртача хезмәт хакы 29,7 мең сум тәшкил иткән.

КАЗАНДА Самосырово бистәсендә чүп-чар яндыру заводы төзелү турында хәбәр халык арасында шау-шу уятты. Россия Президенты Владимир Путинга адресланган петициягә өч көн эчендә 9 меңнән артык кеше имзаларга өлгергән. Халык, заводтан чыккан зарарлы матдәләр җил белән таралып, сәламәтлеккә зыян китерәчәк, дип саный. Билгеле булганча, Татарстанда чүп-чарның бик аз проценты гына эшкәртелә, көнкүреш калдыкларын куярга урын юк. Бүген – 19 гыйнвар көнне, Казанда бу мәсьәлә буенча иҗтимагый тыңлаулар билгеләнгән.

Рафаэль Хәкимов: «Шәймиев игътибар яратмады»

Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов 17 ел буе Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең киңәшчесе булган кеше. Ике дистә ел эчендә ул республика җитәкчесенә нинди киңәшләр биргән? Казанның меңьеллыгын башта исбат итү, ә аннары үткәрү өчен федераль үзәктән акча алу нинди авырлыклар белән бирелгән?

Линар ЗАКИРОВ

tatar-inform.ru

«ҮЗ АКЫЛЫ ДА ҖИТӘРЛЕК»

– Рафаэль Сибгатович, Минтимер Шәймиев сезне үзенә ничек эшкә алырга булды?

– Мине баштарак үзенә Татарстанның шул чактагы премьер-министры Мөхәммәт Сабиров та чакырып карады. «Министрлар Кабинетында фән һәм мәгариф белән шөгыльләнерсең. Килсәң, аерым комитет булдырырбыз», – диде. Күпмедер вакыттан соң, гариза язып, Шәймиевтән виза алырга кирәк булды. Әмма ул: «Кул куймыйм, Рафаэль үземә дә кирәк», – дигән.

– Киңәшче буларак,ниләр эшләргә тиеш идегез?

– Халык киңәшче эшен гади генә бер нәрсә итеп күзаллый. Янәсе, акыллы фикер килде дә, җитәкче янына кереп, шулай эшләргә тәкъдим итәсең. Ә җитәкче шуны үтәргә тиеш, имеш. Һәрвакыт алай була алмый. Кайвакыт Минтимер Шәрипович янына бик акыллы фикер белән керәсең дә, шулай эшләсәң, яхшы булыр иде, дисең. Ә ул: «Бар, үзең эшлә. Хуплыйм», – дип әйтә иде. Минем сәркатибем дә булмады, 17 ел үзем эшләдем.

Минтимер Шәймиевнең үз акылы да җитәрлек. Киңәшче тегеяки бу сәяси мәсьәләне фаразлау өчен кирәк. Бу юлдан барсак, аның нинди уңай һәм тискәре яклары булырга мөмкин, икенче юл белән барып буламы, булмаса, ничек чигенергә кирәк, дип баш ватасың. Минтимер Шәрипович шушы әйберләрне, гади генә итеп, «плюс»лар һәм «минус»лар дип атый иде. Андый фаразларны ярты елга яки күбрәк вакытка төзергә кирәк иде. Тик элек тә, хәзер дә бер ел эчендә нәрсәләрнең ничек булачагын әйтүе авыр.

– Шәймиев, сәясәтче буларак, күз алдыгызда үскәндер...

– Аның биографиясен ике өлешкә бүләр идем. 1990 елга чаклы чорда Минтимер Шәймиев, сәясәттән читтәрәк торып, хуҗалык мәсьәләләренә күбрәк игътибар бирде. Сәясәт бит ул шундый нәрсә: аның белән йә син шөгыльләнәсең, йә бүтән кеше бәреп керә. 90нчы елларда катлаулы вакыйгалар берсе артыннан берсе булып кына торды: ГКЧП, 1992 елгы референдум... Шул чорда Минтимер Шәрипович үзен зирәк сәясәтче буларак күрсәтә алды.

Безнең халыкта бала тәрбияләгәндә, аңа һәрвакыт, «чамаңны, дәрәҗәңне бел, тәртипле бул», дип әйтә килләр. Татар кешесе катырак сөйләгәнне кабул итми. Минтимер Шәриповичка кеше белән җайлап сөйләшү сәләте тел, гореф-гадәтләр белән кереп калган. Калганын өйрәнәсең инде...

Мине дә университетта өйрәткән кеше булмады, җитмәсә, физика факультетында укыдым бит. Үзеңне акыллы дип йөрсәң, андый булып чыкмыйсың шул. Россия Фәннәр академиясе, Гарвард, Бостон югары уку йортларындагы галимнәр белән киңәш-табыш итеп эшләдем. Нәрсәнедер аңламасам, алардан шалтыратып сорый идем. Үз акылың белән генә булмый, кем беләндер киңәшләшергә кирәк. Шәймиев тә: «Бүтән илләргә барыгыз, халыкның ничек яшәгәнен карагыз», – дип әйтә иде.

90нчы еллар башында Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы башка илләр белән багланышлар урнаштыруыбызга каршы булды. Шуңа да партизаннарча эш итәргә туры килде. Берзаман мин – Эстониягә, Татарстан Президентының халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе Тимур Акулов гарәпләр янына китте. Әкренләп кенә чит илләрдә республиканың вәкиллекләрен ача башладык, беренчесе – Литвада, икенчесе Үзбәкстанда барлыкка килде. Бүтән илләрнең уңай тәҗрибәләрен үзебезгә үрнәк итеп алдык. Тора-бара Тышкы эшләр министрлыгы да, Россиягә каршы эшләмәгәнебезне күреп, шушы гамәлләребезгә күнекте.

1994 елда Гарвард университетына бик дәрәҗәле чарага бардык, анда төрле ил җитәкчеләре чыгыш ясады. Чит ил басмалары Татарстан турында баштарак тискәре рухта яза иде, атаклы «Вашингтон пост» газетасы безне «Коммунизм утравы» дип атады. Гарвардта «Татарстан моделе» дигән бренд тәкъдим иткәч, журналистларның безгә карашы үзгәрде. Бераздан «Вашингтон пост» та республикабыз турында «Тотрыклылык утравы» дип язып чыкты. Шуннан соң Татарстанны Казахстаннан да аера башладылар.

«БӘРӘҢГЕНЕ КАЙДА САКЛЫЙСЫҢ?»

– Минтимер Шәрипович районнарга еш йөри иде сыман.

– Миңнеханов та авылларга күп йөри... Әмма теге чорда күп нәрсә җимерек хәлдә, рәткә кертергә кирәк иде бит. Юллар юк, язын-көзен авылларга кереп булмый.

Минтимер Шәрипович авыл хуҗалыгын күтәрү артыннан йөрде. Ачлыкны үткән халык, корылык була калса, дип, бер-ике елга запас әзерли. Әнием дә шундый иде. Үземнең йортны рәткә китергәндә, Шәймиев килде дә: «Базың кайда?» – дип сорады. «Бәй, ул ни эшкә кирәк соң?» – дип аптырап калдым. «Ә бәрәңгеңне кайда саклыйсың?» – диде ул. Бүгенге көндә яшьләргә базда яшелчә саклау бер әкәмәт булып тоеладыр, кибеткә бардың да алдың, дип кенә уйлыйлар.

Минтимер Шәриповичның хатыны Сәкинә Шакировна безгә помидорлар җибәрә иде. Алар бүген дә үз бакчаларында яшелчә үстерә, кечкенә генә парниклары, тавыклары да бар.

– Җитәкчегезнең төнлә шалтыраткан чаклары булдымы?

– Элек эш буенча кичен шалтыраткачы булды, ләкин төнлә түгел. Кичке биштән соң һәм иртәнге тугызга кадәр аны борчырга ярамый иде. Иртән Минтимер Шәрипович газета укый иде. Бүген дә һәр көнен матбугат белән танышудан башлый.

Минтимер Шәрипович кешене тыңлый белә. Янына берәр мәсьәлә буенча керсәң, «Минем аргументларым бар, ләкин башта сезне тыңлыйм әле», – дия иде. Син сөйләп бетергәч, ул: «Ә моны сез уйлап бетермәгәнсез, өстәмә аргументым бар», – дип киная белән әйтә иде. Ул һәр мәсьәләнең төбенә төшә. «Аңлатыгыз миңа. Мин аңламасам, халык ничек аңласын?» – ди иде.

Минтимер Шәрипович кәгазьгә карап чыгыш ясарга яратмады. Юлламаны, мөрәҗәгатьләрне генә укый иде. Аны кайвакыт оппозициягә катырак әйтә иде, дип тәнкыйтьлиләр. Юк, ул, киресенчә, оппозиция арасыннан талантлы кешеләрне үзе янына туплый белде.

«БҮЛӘК АЛЫРГА ЯРАТМАДЫ»

– Казанның меңьеллыгын үткәрү ни дәрәҗәдә авыр бирелде?

– Мәскәүдә моңа көлеп карадылар. Башкалабызның меңьеллыгын без генә түгел, Россия Фәннәр академиясе дә танырга тиеш иде. Мәсьәләнең фәнни һәм сәяси якларын хәл итү минем өстә булды. Академия галимнәре белән уртак тел табу җиңел булмады. Алар безгә элегрәк Казанның 800 еллыгын уздырырга рөхсәт биргәч, 1000 еллыкка дәгъва итүебезгә бик аптырадылар. Шуңа да карамастан, экспедицияләре килеп, Кремль янында казу эшләре алып барып, Казанның, чыннан да, меңьеллык тарихка ия икәнлегенә ышанып, исбатлап, безне яклап чыктылар. Фәннәр академиясе президиумындагы 20 академик та уңай тавыш бирде, моны фәнни ачыш дип атады.

Казанның меңьеллыгын Россия «Саклык банкы» идарә рәисе Герман Греф Россиянең иң эре инвестицион проекты дип атады. Бу чарага 80 миллиард сум тотылды.

Сәяси яктан да Мәскәү белән килештек. Бәйрәмне оештыру комиссиясе җитәкчесе итеп ул чактагы Россия премьер-министры Владимир Путин билгеләнде. Шул чорда ул президентлыкка дәгъва кылды, әмма премьер-министр буларак агитация алып бара алмый иде. Ә Татарстан сайлау алдыннан әһәмиятле төбәк, безгә башка регионнар да карый. Шуңа да сайлау алдыннан Путинның шушы комиссияне җитәкләве сәяси адым булды. Ул, меңьеллыкны ничек уздырабыз, дип Казанга килеп, комиссия утырышын да үткәрде.

Илбашы булып сайлангач, Владимир Путинга рәислектән баш тартырга уңайсыз булды. Меңьеллыкка үзе килде, шуңа күрә инвестицияләр дә күп кертелде. Безнең өчен бик зур адым булды. Бу чарадан башка Универсиаданы үткәреп булмас иде.

– Минтимер Шәрипович туган көннәрен ничек үткәрә иде?

– Ул туган көнендә Казаннан китә иде. Игътибар да, бүләк тә алырга яратмады. Берсендә, командировкадан кайтып барганда, Минтимер Шәриповичны үзенең туган көнендә очраклы рәвештә Мәскәүдә күреп алдым. Вәкиллектә унлап кеше аның гомер бәйрәмен үткәрдек.

Хыяллар тормышка ашканда

2009 елның 30 декабре, сәгать кичке алты.

Яңа елның үз вазифаларына керешер вакыты җитеп килә, Мәскәү Кремлендә хөкүмәт әгъзалары Яңа елны каршы алырга җыена. Шунда Россия премьер-министры Путин Татарстан Президенты Шәймиевне кабул итте.

Керә-керешли дип әйтерлек, Минтимер Шәрипович сүз башлады:

– Владимир Владимирович! Сез беләсез инде, мин Президентлыктан китәргә булдым, – диде. – Беләм, Казан сезгә бик ошый, Казан Кремлендә собор чиркәве белән янәшә мәчет басып тора. Сез безгә чит ил вәкилләрен, чит дәүләт башлыкларын юллыйсыз. Без толерантлык үрнәге булып торабыз, төрле дин тоткан милләтләрнең үзара дус, тату яшәү үрнәге башкаларга да бик кирәк. Бездә ике һәйкәл, федераль әһәмияткә ия ике дин йорты. Әйдәгез, шуларны торгызып, матурлап, бөтен җиргә күрсәтик әле! Иделгә сәяхәтчеләр күпләп килә, шулай эшләсәк, сәяхәтчеләрнең саны күпкә артачак. Ә сез бүлеп биргән 15-16 миллион сум акча биналарны җимерелүдән туктатыр өчен дә җитми. Ә бу һәйкәлләр бит федераль әһәмияткә ия. Әйдәгез, иллегә илле булсын!

– Ничә сум кирәк? – дип сорады Путин.

– Өч-дүрт ел дәвамында, һич югында, яртышар миллиард.

– Һәр бина өченме?

– Юк, еллык бюджет. Аермаенча. Без Кремльне дә шулай аякка бастырдык. Бу бик тә кирәкле гамәл. Без фонд оештырырбыз, калганы халыкның ирекле рәвештә кергән акчасына булыр. Мин ышанам, халык безгә терәк булыр, дим.

– Әйдәгез болай итик – бер елга 400 миллион! Федераль бюджеттан һәм тәңгәл күләмдә Татарстан бюджетыннан.

Шәймиев, сүзне озакка сузмыйча, риза булды.

Менә шуннан Бөек Болгар белән Зөя каласын торгызу эше башланды.

Бу гамәлләр Татарстанны килеп күрергә теләүче сәяхәтчеләрнең санын күпкә арттырды. Ә иң әһәмиятлесе – Шәймиевнең әлеге гамәлләре халык күңеленә хуш килде!

Рабит БАТУЛЛАның «Илбашы» китабыннан.

Аксакалга мәдхия

Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА, *пенсионер, Азнакай районының Беренче Май авылы:*

– Мин үзем гомер буе колхозда сыер саудым. Хәзерге вакытта лаеклы ялдамын. Минтимер Шәймиев акыллы җитәкче булды. Ул Президентлык иткән елларда авыл халкына пай җирләре бирелә башлады. Бу бик яхшы ярдәм булды, аның бүген дә файдасы зур. Элек кеше башына 50 кг гына ашлык бирәләр иде бит. Пенсиядәге кешегә анысы да эләкми иде әле. Ә хәзер, пенсиядә булсак та, икмәген алып торабыз. Кешеләр, әллә кайчан гүр иясе булган әти-әниләренең пай җирләрен рәсмиләштереп, шуның файдасын күрә.

Дилә ГЫЙЛЬМАНОВА, *Казан шәһәре, Абдулла Алиш исемендәге 20нче гимназиянең 6 В сыйныфы укучысы:*

– Минтимер Шәймиев – Дәүләт Киңәшчесе – үзенең акыллы киңәшләре, тәҗрибәсе белән Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка булыша. Мин аны якыннан күреп белмим, ләкин телевизордан карап та Минтимер Шәймиевне ачык күңелле, әйбәт кешедер, дип уйлыйм. Аның йөзендә иман нуры бар, кешеләрне яратуы күренеп тора. Мин аны Кыш бабайга да охшатам әле. Ул да бит бик юмарт һәм балаларны ярата.

Илһамия НУРЕТДИНОВА, *пенсионер, Балык Бистәсе районының Балтач авылы:*

– Чит дәүләтләрдә яки үз илеңнең башка төбәкләрендә яшәгәндә генә туган җиреңнең җанга газиз, кадерле булуын бөтен барлыгың белән аңлыйсың.

Илле елга якын гомерем Себер якларында узды. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевне Себердә дә ишетеп-танып беләләр иде. Ул 1990 елларда үзенең зирәклеге белән Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россия күләмендә милләтара тынычлыкны саклап калды, дип саныйм. Аллага шөкер, туган авылыма кайтып яши башлавыма да биш ел вакыт узды. Туган җир җылысы җанга-тәнгә көч биреп тора ул. Татарстанда милләтара дуслык булуына сөенәм, республиканың бүгенге җитәкчелегенең дә эшләрен хуплыйм. Россия көчле булсын, юлыбыз да, бәхетебез дә бер.

Каш уйнатып әйткәннәр

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ АФОРИЗМНАРЫ

✓ Без булдырабыз!

✓ Мин начар кеше түгел, әмма ул кадәрле үк яхшы да түгелмен.

✓ Картайган саен, иптәшең сиңа кадерлерәк, якынрак була.

✓ Без тормыш күргән, шуңа эшләребез уңышлы.

✓ Кешеләрне яратмасаң, хакимияткә килмә. Килгәнсең икән хакимияткә – зарланма, кешеләргә хезмәт ит.

✓ Мин гел әйтә киләм: кешегә бервакытта да артыгын вәгъдә итәргә кирәкми. Азрак әйтеп, күбрәк эшләсәң – иң кыйммәте шул. Бу очракта халык сүзеңә ышана. Төрле хәлләр булырга мөмкин, шуңа күрә чигенергә дә урын калырга тиеш.

✓ Сүзен-сүзгә тәрҗемә итсәң, Минтимер ул «Мин» + «тимер» була. Тимер кеше. Трактор дисәң дә була инде.

✓ Бездә кычытмаган җирне кашыма дигән яхшы гына гыйбарә бар. Кашыган җирдә гел бер әйбер барлыкка килми калмый.

✓ Владимир Владимирович Путинны мин беренчеләрдән булып хупладым. Ул илне безнең Татарстандагы кебек тәртипкә китерәчәк дип уйладым.

✓ Мин драматург була алмадым, драматургиясе бар-барын, әмма роле башка.

✓ Юбилей – минеке, әмма еллары – минеке түгел.

✓ Син кешене уңышлы эшләгән җиреннән алып башка, югарырак эшкә куясың икән, син аның язмышына кагыласың дигән сүз. Яңа урында аның нидер барып чыкмый икән, менә шул чакта онытмаска кирәк аның турында. Мин чакырдым, димәк, мин аның өчен җаваплы.

«Социаль ипотека программасы өчен Минтимер Шәймиевкә бик рәхмәтлебез», – ди Бәйрәмовлар.

Кайчандыр иске агач өйдә яшәгән Хәзирә апа белән Шәйхулла абый тузган торак программасы ярдәмендә өр-яңа фатирлы булуларына бүген дә сөенә.

Идар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Иң зур шатлык – торыр урының булу»

Меңнәрчә гаиләнең иң зур хыялын тормышка ашырган – фатирлы иткән «Социаль ипотека» белән «Тузган торак» программалары өчен Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә халык әле хәзер дә рәхмәтле. «Тузган торак» программасы буенча ун ел эчендә республикада 49868 гаилә бушлай фатир ала. 2005 елдан 2016 елга кадәр исә социаль ипотека программасы буенча барлыгы 118 мең гаилә тораклы булды.

Эльвира МОЗАФФАР

ҮЗ КЕШЕБЕЗ СЫМАН

– 1993 елда хөкүмәт, ун елга исәпләнгән программа буенча, тузган торактан күчерелергә тиешле йортлар графигын төзегән иде. Әмма программа начар үтәлде. Депутатлар Президентка ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәч, Минтимер Шәймиев, актив төркемне җыеп: «Бу эшне хөкүмәт кенә башкарып чыга алмый, яңа фонд булдырырга кирәк», – дип тәкъдим итте. 1995 елның 30 мартында тузган торакны бетерү буенча бюджеттан тыш фонд булдыру турында 913 нче номерлы указ имзаланды. Соңрак, шушы фондны төзү өчен, мине директор итеп куйдылар. Президент аппараты, хөкүмәт белән берлектә, фондның нигезләмәсен ясадык, – дип искә ала Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды директоры киңәшчесе Мидхәт Шәрифуллин.

Аеруча Казанның үзәк урамнарында җиргә сеңеп барган йортларда яшәүчеләр өчен яңа төзелгән район – Азино якларындагы иркен торакларга күчүнең зур шатлык булган. 1997 елдан фондны Тәлгать Абдуллин җитәкли башлаган.

Тузган торак программасының үтәлеше белән танышырга 2000 елда Казанга ул чакта Россия Президенты вазифаларын башкаручы Владимир Путин да килгән булган. Минтимер Шәймиев белән алар тузган торакта яшәүче Хәзирә апа белән Шәйхулла абый гаиләсендә булганнар. Без бу гаиләне эзләп таптык. Инде 75 яшенә җитсә дә, истәлекле вакыйганы яхшы хәтерли Шәйхулла абый Шәрифуллин.

– Хәзирә белән хәзерге «Сукно бистәсе» метро тукталышыннан ерак түгел, Свердлов урамындагы агач йортта яшәдек. Суны чиләкләп ташыйбыз, бәдрәф урамда иде. Аның каравы газ кергән, ишегалдыбыз иркен, чия агачлары үсеп утыра, тавыкларыбыз бар. Владимир Путин белән Минтимер Шәймиев киләсен бер ай алдан әйттеләр безгә. Аңа хәтле Татарстан Президентын май комбинаты төзелешендә берничә тапкыр очратканым булды. Минем үз оешмам бар иде, без цехлар төзетү белән шөгыльләндек. Минтимер Шәймиев – ипле, ярдәмчел, җайлы, кешелекле, үз кешебез сыман ул. Шуңа да җитәкчелек килә дип әлләни борчылмадык. Хатыным Киров исемендәге заводта эшли иде. Ул кунакларны чәк-чәк белән каршы алды. Өстәл әзерләп йөргән хатынымны күреп, Путин: «Җәмәгатең ник утырмый?» – дип сорап куйды. Минтимер Шәймиевнең: «Безнең татарларда шулай гадәтләнгән инде, хатын-кызлар ир-атлар белән бергә утырмый», – дип шаяртканы истә. Ә Владимир Путин: «Ул утырмаса, мин дә утырмыйм», – дип, Хәзирәне барыбер утыртты. Россия Президентының кайнатма белән яратып чәй эчкәнен хәтерлим. Оныгыбызга ел символы – уенчык аждаһа да бүләк иткән иде. Икенче көнне үк безгә хәзерге Назарбаев урамындагы йорттан яңа фатирдан ачкычлар тапшырдылар. Минтимер Шәймиев күрсәтмәсе булмаса, бу шулай тиз эшләнер идеме икән? Бүген дә фатирыбызга сөенәбез. Мин Поляр арьягында шахтер булып эшләдем. 55-60 градус салкыннарда да хезмәт итәргә туры килә иде. Сәламәтлегем нык какшады. Картаймыш көнемдә барлык шартлар тудырылган йортта яшәү – бәхет инде ул, – ди Шәйхулла абый.

«МОНДЫЙ ЙОРТ БЕРКАЙДА ЮК»

Көнкүрештә торак шартларын яхшырту буенча Дәүләт Советы тарафыннан 2004 елның 27 декабрендә яңа закон кабул ителгән.

– «Егетләр, программа үтәлә бит, халыкка ярдәм итү өчен яңасын табарга кирәк», – дигән тәкъдим белән чыкты Минтимер Шәймиев. Нәтиҗәдә социаль ипотека программасы барлыкка килде. Минтимер Шәймиев гел: «Ташламалы фатирлар булдыру – безнең изге бурыч», – дип кабатлый иде. Программа расланганчы ук, тәҗрибә өчен аны Чаллыда сынап карадылар. 2003-2004 елларда анда беренче тораклар куллануга тапшырылды, – дип искә ала Мидхәт Шәрифуллин.

Ни хикмәт, ул чакта социаль ипотека белән фатир алырга теләүчеләр булмый диярлек. Бушлай торак өмет итүчеләр, кредит аз процент ставкасы белән тәкъдим ителсә дә, социаль ипотека буенча

– Кеше өчен иң кирәкле нәрсә, иң зур шатлык бит ул – торыр урының булу. Без Рәсәйдә шундый программаны тормышка ашыра алган бердәнбер төбәк булдык. 20 елдан артык вакытка 7 процентлы ипотека бирүчеләр әле хәзер дә юк. Тузган торакны бетерү программасын тәмамлагач, социаль ипотекага керештек. Аллага шөкер, рәхмәт сүзләрен еш ишетергә туры килә. Тузган торакны гына алыйк. Үз гомерләрендә беренче тапкыр зур, якты, бар уңайлыклары булган фатирларга күчкән кешеләрне күргәч, күңел тетрәнә иде. Ул гаиләләргә барып, күреп йөрдем. Үзем дә алар өчен чын күңелдән шатландым. Үз куышың булу яшәргә көч бирә. Тормыш булгач, төрле хәлләр килеп чыга, тик бу кыйммәтләрне бер нәрсә белән дә алмаштырып булмый.

– Әлеге программаны өйрәнергә башка төбәкләрдән дә килгәннәр, диләр, тик аларда ул барып чыкмады. Безнең уңышның хикмәте нәрсәдә булды икән?

– Дөресен әйтергә кирәк, күпләр тырышып карады. Башкортстаннан Мортаза Рәхимов та делегацияләр җибәреп өйрәнде. Свердловск өлкәсе губернаторы Эдуард Россель кат-кат кызыксынып карап китте. Башкалар да булды... Омтылышлары зур иде, мөмкинлекләре дә юк түгел. Бу эштә иң мөһиме – зур салым түли торган компанияләр җитәкчеләре белән аңлашу. Бездә дә төрле чаклар булды, аңлашылмаучылыклар да килеп чыкмады түгел, тик ахырда барысы да, бу программаның әхлакый мәгънәсенә төшенеп, ризалык бирде. Компания җитештергән продукция күләменнән бер процент кереме Тузган торакны бетерү программасына бүлеп бирергә дип килештек. Ул вакытлар өчен шактый зур сумма: елына 16-17 миллиард сум җыела иде. Ни өчен мине гаепләргә омтылучылар булды? Чөнки бу федераль бюджетка китә торган салымнарны бер процент чамасы киметү дигән сүз иде. Гаепләүләргә җавап итеп, мин ачыктан-ачык: «Алайса, кешеләрне тузган торактан нормаль шартларга чыгарган өчен, ачык суд ясагыз», – дидем. Шуннан соң Россия прокуратурасы бу хакта башка сүз кузгатмады.

Минтимер Шәймиевнең «Шәһри Казан» газетасына биргән әңгәмәсеннән, 2015 ел, июнь.

тапшырылган йортларга күченергә ашыкмыйлар.

Мидхәт Шәрифуллин әйтүенчә, Минтимер Шәймиев программа үтәлешен шәхсән үзе контрольдә тоткан. «Атнасына ике, өч тапкыр Мидхәт Абдуллинны кабинетына чакыртып, хисап ала, аның сөйләгәннәрен тыңлап, үзенә нәтиҗәләр ясый иде. Базар мөнәсәбәтләренә күчү сәбәпле, халыкка бушлай фатирлар өләшеп булмый, ләкин торакка мохтаҗларга ташламалы методика белән программаны үтәргә кирәк», – дия иде Минтимер Шәрипович», – ди ул.

Казанда социаль ипотека программасы буенча тапшырылган беренче йортлар арасында Имәнлек урамындагы 11нче йорт та бар. Шәймиев әлеге төзелешне гел килеп карап йөргән, фатирлар тапшыру тантанасында да катнашкан. «Без уйлаган фикерләрне –ташламалы фатирлар алып булуны раслады бу йорт. Торакка мохтаҗ һәркемгә мондый фатирлар тапшырырга тиешбез», – дигән ул ачылыш вакытында. Минтимер Шәймиев, мэр Илсур Метшин һәм дәрәҗәле җитәкчеләр композитор, җырчы Вәис Бәйрәмовлар гаиләсе яши башлаган өч бүлмәле фатирда да кунак булганнар. Әлеге вакыйганы Бәйрәмовлар бүген дә дулкынланып искә ала.

– Хатыным Гөлсем – укытучы, ике ул үстерәбез. Өйләнешкәч, Казан дәүләт педагогика институтының тулай торагында, коммуналь фатирда, «хрущевка»да гомер кичерергә туры килде. Социаль ипотека программасы турында почта әрҗәсенә салынган игълан кәгазьләреннән укып белдек. Бәхетебезне сынап карыйк дип, икеләнеп кенә, документларны тапшырдык. Түләп бара алырбызмы, дип тә курыктык. Бер ел дигәндә, өч бүлмәле фатирлы булдык. Безнең өчен көтелмәгән бүләк булды бу. Беренчел кертемебез дә 100 меңгә генә якын иде. Мондый программа өчен Минтимер Шәймиевкә бик рәхмәтлебез, – ди Вәис Бәйрәмов.

Хатыны Гөлсем ханым:

– Президент үзе киләсен белгәч, бик борчылдык инде. Ә Минтимер Шәймиев белән сөйләшә башлагач, өстән тау төшкәндәй булды. Сөйләшү бик җиңел барды, шундый җылы очрашу иде ул, Минтимер Шәриповичның ихласлыгына, гадилегенә сокландык, – ди.

Минтимер Шәймиевнең өй туена биргән бүләкләрен дә хәтерли алар.

– Кечкенә улыма уенчык машина, олысына ноутбук, хатыныма чәчәкләр бүләк иткән иде. Йомшак диван, аш бүлмәсенә гарнитур да бирде әле. Шаяртырга яратуы да истә калган. Табын артында чәй эчеп утырганда, сезнең дүртегезнең дә күзләре зәңгәр икән, диде, – дип искә ала гаилә башлыгы.

Ул чакта Минтимер Шәймиев Вәис Бәйрәмовның гармунда уйнавын сокланып тыңлаган, кечкенә уллары Газиз пианинода уйнап күрсәткәннән соң, үзе дә клавишаларга баскалап көй чыгарган.

Имәнлек урамындагы 169 фатирлы әлеге йорт табигатьнең гаҗәеп гүзәл урынында – урман янәшәсендә урнашкан. Биредә табиблар, артистлар, мәдәният эшлеклеләре, журналистлар, хокук саклау органнары хезмәткәрләре яши. Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында эшләүче 16 гаилә дә шуннан фатир алган. Йортның рәисе, озак еллар Татарстанның Дәүләт Советында эшләгән Сиринә Петренко: «Мондый йорт республикада гына түгел, Союзда да юк», – ди, уенын-чынын бергә кушып.

– 2016 елда йортка ун ел булды. Без бу дата уңаеннан бәйрәм оештырдык. Артистларыбыз Зөлфия Вәлиева, Фәридә-Алсу дуэты, Тинчурин театры артистлары концерт куйды. Йортыбызның уңган хуҗабикәләре пироглар пешереп чыкканнар иде. Гомумән, төрле милләт халкы дус, тату яшибез. Элегрәк урамнардан флаглар күтәреп тә уза идек әле, күмәкләшеп урманга чана, чаңгы шуарга барабыз. Кышкы сабантуйлар оештырабыз, милли уеннар уйныйбыз. Казанның 18нче хастаханәсенең баш табибы урынбасары Рөстәм Бакиров һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер. Балаларга чаңгылар, энциклопедияләр бүләк итте. Ел саен беренче сыйныфка укырга керүче балаларга букчалар тапшырыла. Биредә яшәүчеләр һәр нәрсәнең кадерен белә, – ди Сиринә ханым.

Җаваплылык

Заманында Бауман райкомында эшләгән вакыттан ук, Хәбир Иштирәков Минтимер Шәймиевне яхшы белгән. Ул райкомда инструктор буларак, булачак Президент идарә иткән министрлыкның кураторы була. Язмыш аны Минтимер Шәрипович белән яңадан 2000 елның маенда очраштыра.

Хәбир Иштирәковны Президент аппаратының гражданнарны кабул итү һәм хатлар бүлеге мөдире итеп чакыралар (соңрак ТР Президентының гражданнарның мөрәҗәгате белән эшләү буенча идарә башлыгы. – **Ред.**). Үзе эшли торган Татарстан Дәүләт Советыннан китәсе килмәсә дә, Президентның эш кабинетына сөйләшүгә чакырылгач, аның өстәл артыннан чыгып, елмаеп: «Мин бит сине беләм, эшеңдә уңышлар телим», – дип аның кулын кысканнан соң елмаеп, ризалыгын белдерә.

Мондый вазифа зур җаваплылык таләп итүгә карамастан, Хәбир Иштирәков Минтимер Шәймиев белән эшләгән елларын сагынып искә ала. Аның гаҗәеп шәхес булуына бергә эшли башлагач кат-кат инана.

Хатлар бүлеге, Президентны халык белән бәйләүче чылбыр буларак, нинди генә мөрәҗәгатьләр кабул итми ул чакта! Берсе дә җавапсыз калмый, ә республика җитәкчесе ярдәменнән башка чишәргә мөмкин булмаган мәсьәләләр күтәрелгәннәре аңа юллана.

– Аның шул хатларга карата булган игътибары мине гаҗәпләндерә иде. Укыганда аерым җөмләләрнең астына сызып, кырыйларына аерым фикерләрен, тәкъдимнәрен язып куя иде. Аннары шул үтенеч-гозерләрнең үтәлеше белән кызыксынып торды. «Ә син ничек карыйсың?» – дип сораудан да кимсенеп тормады, – дип искә ала Хәбир Иштирәков. – Минтимер Шәрипович халык белән еш аралашты. Әгәр үзенә максат куя икән, җаваплылыктан курыкмады. Кадрлар мәсьәләсендә дә кешене алдан күрә белгән шәхес. Бүгенге Президент Рөстәм Миңнеханов, премьер-министр Илдар Халиков, Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин – Минтимер Шәймиев мәктәбен үткән җитәкчеләр. Эшләү дәверендә мине тагын бер гаҗәпләндергән кеше – Сәкинә ханым. Ул да ярдәмчел. Кеше белән аралашмыйча тормыйсың бит инде, бервакыт миңа шалтыратып: «Фәлән кешегә булышып булмасмы икән?» – дип сораганы истән чыкмый. Әмма шунысы хак, Сәкинә ханым – иренең абруен тота белгән хатын, аның эшенә беркайчан да кысылмады.

Хезмәт кешесенә беркайчан да битараф булмый Беренче Президент. Пенсиягә чыкканчы Буа районында сыер савучы булып эшләгән бер ханым өенә газ кертүдә ярдәм сорап хат яза. Өй эчен газлаштыру кешенең үз хисабына башкарыла. Әлеге проблема белән танышкач, Шәймиев шунда ук мәсьәләне хәл итәргә боерык та бирә. Аның ярдәме белән уңай хәл ителгән мисаллар: янгын чыгудан зыян күрүчеләрме, армиядә хезмәт итү буенчамы, юл төзү буенчамы… алар санап бетергесез.

– Минтимер Шәймиев, гомумән, халыкны ярата. Халык та ул яратуны һаман да тоеп яши. Минем белән Татарстанның Ветераннар берлеге рәисе буларак та хәзер дә аралашып, эшебез белән кызыксынып, хәлләрне сорашып тора, – ди әңгәмәдәшем.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Нургаян АСКАРОВ, 80 яшь, лаеклы ялдагы колхозчы-пенсионер, Балтач районының Арбор авылы:

– Мин Минтимер Шәймиев турында беренче тапкыр ишетеп белә башлаганда, ул мелиорация өлкәсендә эшли иде. Аны бик яхшы җитәкче булды дип саныйм. Авылларга газ кертүне генә алыйк. Авыл халкының яшәешен тамырдан үзгәртте бит. Бу сиңа кайдадыр бер күпер ачу гына да түгел. Анысы да кирәк, сүз дә юк, шулай да авылларга газ кертү кебек программалар – бөтен республика халкына турыдан-туры тәэсир иткән зур эшләр. Аның малае Радик Шәймиевнең бездә йоклап чыкканы да бар әле. Студентлар ул вакытта авылларга эшкә килә иделәр, күп вакыт аларны безнең иске өйгә кертә торганнар иде. Ул күрше авылга билгеләнгән булган, иптәшләре янына кунакка килгән иде.

Зәрия ХӘСӘНОВА, ферма мөдире, Ютазы районының Кәрәкәшле авылы:

– Шәймиев – безнең кода ул. Әниемнең абыйсының кызы Лилия – Беренче Президентыбызның абыйсы Хантимернең улы Алмазда кияүдә. Алар Чаллыда яши. Алмаз һәм Лилия белән бик сирәк күрешәбез, дөрес, элегрәк гаилә бәйрәмнәрендә ешрак очраша-аралаша торган идек. Алмаз, Президент туганы булуга карамастан, үзен гади тота. Минтимер әфәнде белән күзгә-күз карап аралашканыбыз булмаса да, шундый данлыклы гаилә белән туганлашуыбыз, кодалар булуыбыз белән горурланам.

Таһир ӘШРАПОВ, Түбән Кама шәһәре, Бакый Урманче исемендәге 2нче гимназиянең 5 Б сыйныфы укучысы:

– Мин бик бәхетле малай, миндә Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев бүләк иткән каләм бар. Быел «Глаголица» Бөтенроссия ярышында катнашкан идем. Без әти-әнием белән бергәләп, «Тукай белән сөйләшү» дигән өч минутлык фильм төшердек. Баш рольне мин уйнадым. Менә шушы эшебезне Минтимер Шәрипович та күргән, бик ошаткан, махсус бүләк тә әзерләгән. Әлеге мәртәбәле конкурсның йомгаклау тантанасында аның ярдәмчесе Нурсөя апа Шәйдуллина кулыннан ул кадерле бүләкне алганда бик дулкынландым. Шундый зур абруйлы дәүләт эшлеклесенең гади укучы малайга шундый зур игътибар күрсәтүе каушатты да хәтта. Хәзер бу бүләк-каләм мине яңа уңышларга дәртләндереп тора, мин аны бик кадерләп саклыйм. Киләчәктә, зур үскәч, мин дә республикабыз җитәкчесе яки берәр министр булырмын да шушы каләм белән бик мөһим документларга имза салырмын дип тә хыялланам.

«Тукай минем өчен Пәйгамбәргә тиң»

яки Минтимер Шәймиевнең татар мәдәниятенә мөнәсәбәте Разил Вәлиев күзлегеннән

Татар халкы республиканың Беренче Президенты Минтимер Шәймиевне әдәбият-сәнгать дөньясын, аның нечкәлекләрен аңлап-тоеп яшәгән җитәкче буларак белә. Мәдәниятнең кайсы гына тармагы булмасын – әдәбиятмы, театр, музыка-эстрадамы, рәсем сәнгатеме – ул бервакытта да алардан читтә калмады, иҗат әһелләренә гел ярдәм итеп килде. Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев белән Минтимер Шәймиевнең татар мәдәниятенә булган мөнәсәбәте турында сөйләшкәндә, моңа тагын бер кат инандык.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Разил Исмәгыйлевич, Минтимер Шәймиев президентлык иткән елларда татар мәдәниятенә дәүләт дәрәҗәсендә күрсәтелгән ярдәм турында искә төшереп китик әле.

– Иң элек шуны әйтик, Минтимер аганы күбрәк сәясәтче, республика җитәкчесе буларак искә алалар, әмма аның рухи дөньясы, әдәбият-сәнгать өлкәсе белән бәйләнешләре турында җитәрлек дәрәҗәдә сөйләнде, дип әйтә алмыйм. Борын-борын заманнарда ук ил-дәүләт җитәкчеләре фәлсәфәчеләр, шагыйрьләр, язучылар, мәгърифәтчеләр булганнар. Минтимер Шәрип улын да мин шулар белән янәшә куяр идем. Ә инде дәүләт дәрәҗәсендәге ярдәм дигәндә, беренчәсе турында әйтеп китәм. Бервакыт язучыларның күп томлыкларын чыгару бөтенләй тукталган иде. Язучының мирасын туплап бирә торган әлеге томлыкларны кабат чыгару мәсьәләсендә, беренчеләрдән булып, Минтимер Шәймиев ярдәм итте. 2000 еллар башында шактый күп томлыклар бастырылды һәм бүген дә әлеге эш дәвам итерелә. Аннан соң, унбиш еллар чамасы элек, республикадагы китапханәләрне оптимальләштерү, 400 китапханәне ябу турында хөкүмәт карары чыкты. Мин бу эшкә каршы төшеп, мәсьәләне сессиядә күтәреп чыккач, Президент: «Моны ныклап өйрәнергә кирәк», – дип, министрлыкларга күрсәтмә бирде. Мәсьәлә җентекләп тикшерелгәч, әлеге карар гамәлдән чыгарылды. Ә яңа бюджет системасына, базар мөнәсәбәтләренә кергәннән соң, Башкортстан белән Татарстанда гына язучылар оешмаларына бюджеттан акча бирү сакланып калды. Монда да Беренче Президентыбызның өлеше зур. Бүгенге көндә Татарстан китап нәшриятына дәүләттән ел саен 52 млн сум чамасы акча бирелә. Бу яктан Татарстан – Россиянең бөтен төбәкләренә үрнәк.

ТАТАРСТАННЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВНЕҢ ХӨРМӘТ ИТКӘН ШӘХЕСЛӘРЕ
*Шигърияттә – **Габдулла Тукай**, прозада – **Әмирхан Еники**, музыкада – **Салих Сәйдәшев**, рәсем сәнгатендә – **Бакый Урманче**, җырда – **Илһам Шакиров**, театрда – **Шәүкәт Биктимеров** һәм драматургиядә – **Туфан Миңнуллин**.*

– Минтимер Шәймиевнең театрга булган мәхәббәтен, аның Сәкинә ханым белән Камал театры премьераларын калдырмавын беләбез. Шунда ук гаиләгез белән сезне дә күрергә мөмкин. Спектакль тәмамланып, пәрдә төшкәч, сез нинәр хакында сөйләшәсез?

– Театрга гаиләң, фикердәшләрең белән баруның әйтеп бетергесез бер рәхәте бар аның! Театр карау ул әле спектакльнең башы гына! Аның иң кызыгы – шул театрдан соң фикер алышу. Спектакльне карап чыкканнан соң, без барыбыз бергә театрның чәй бүлмәсенә кереп, аны озаклап, тәмләп сүтеп җыя башлыйбыз. Минтимер Шәрипович монда да үзен тыйнак тота, чөнки һәр артистның үзенчәлеген тотып ала һәм бик тә дөрес бәя бирә белә. Әлбәттә инде, мондый вакытта бәхәсләр дә, каршылар туып тора. Әмма ул шуның белән кызык та бит! Тагын бер нәрсә турында әйтми булмый. Акча янчыгы акча салыр өчен уйлап табылган, ә күңел рухи байлык туплар өчен бирелгән. Кесәсе буш хәерче кешене беркем дә хөрмәт итмәгән кебек, күңеле буш кеше шулай ук дан-дәрәҗәгә, ихтирамга ирешә алмый. Бу яктан караганда, Минтимер Шәймиев – рухи яктан искиткеч бай кешеләрнең берсе. Мәсәлән, шул ук театр турында сүз чыкса, аның белмәгән артисты юк. Артистның үзен генә түгел, аның гаиләсенең, балаларының исемнәренә кадәр белә ул.

– Минтимер Шәймиевнең шәхес буларак үсешенә кайсы әдипләрнең китаплары ук тәэсир итте икән? Ул турыда сезгә әйткәне булдымы?

– Әгәр аның эш бүлмәсенә керсәгез, бөтен җирдә китап өемнәрен күрерсез. Чираттагы бер очрашуыбызда мин аңардан: «Минтимер әфәнде, Сез боларны укырга вакыт таба аласызмы соң?» – дип сорадым. «Башка нәрсәгә тапмасам да, боларга мин вакыт табарга тиеш», – диде ул. Карыйм, иң өстәлендә Тукай китабы ята. Үзем дә аңа «Тукай турында ядкарьләр» дигән ике томлык алып кергән идем. Шуңа бик сөенде һәм: «Тукай минем өчен Пәйгамбәргә тиң, – диде. – Мин аны гомер буе укыйм һәм еллар узган саен, шагыйрьнең кадере арта гына бара. Миңа калса, кеше Тукайны гомере буена да ачып бетерә алмый торгандыр. Мин аны борчылганда укысам, тынычлык табам, шатлыклы вакытларымда – сөенечләремне уртаклашкандай булам. Теләсә кайсы халәттә дә Тукайны укып, аннан ләззәт алам». Ә инде язучылардан, белүемчә, Әмирхан Еникине яратып укый. Аның үзендә дә әлеге халык язучысыныкы кебек нечкә тоемлау хисе бар. Хәзерге вакытта ул тарих белән бик нык кызыксына.

– Аның кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов һәм казакъ шагыйре Олжас Сөләйманов белән дуслыгы турында укып, ишетеп беләбез. Ә татар язучылары арасында шундый фикердәше бармы?

– Ул бик күп язучылар белән аралаша. Әмма иң еш очраша-аралаша торган кешесе Туфан ага Миңнуллин иде. Аның вафатыннан соң без документаль фильм төшерү идеясе турында әйткәч, ул: «Бик дөрес. Туфан – Туфан инде ул», – диде. Фильмның исеме дә шуннан барлыкка килде. Туфан аганы ул, турысын бәреп әйтүенә карамастан, кеше буларак та ихтирам итә иде. Туфан ага, килешмәгән очракта, башкалар кебек баш селкеп, «әйе-әйе» дип тормый, үз сүзен, фикерен әйтә торган иде. Һәм Минтимер әфәнде вакыт-вакыт аның белән килешмичә дә булдыра алмый иде. Гомумән, ул язучыларга бик тә якын кеше. Язучылар авырып китсә, кыен хәлдә калса, без иң беренче чиратта, Президентка мөрәҗәгать итә идек. Һәм аның бервакытта да ярдәм итмичә калганы булмады.

– Минтимер Шәймиев Язучылар союзы корылтаеннда да даими катнашып килде. Корылтай алдыннан Язучылар берлегенең иң актив әгъзалары белән дә очраша иде.

– Дөрес, һәр корылтай алдыннан без 15-20 кеше Президент белән очраша идек. Әмма алай гына да түгел, ул һәр җәйнең бер көнендә җәмәгать эшләрендә актив катнаша торган унлап шәхесне үзенә чакырып, учак янында бик иркенләп сөйләшү оештыра иде. «Галстукларыгызны салып ташлагыз һәм күңелегездә нинди фикер, уй-теләкләр бар – барысын да турыдан-туры әйтегез», – дип әйтә иде. Мондый ачылып китеп сөйләшүләрдә, үзе кайвакыт безнең белән килешмәсә дә, башка таяк белән сукмый иде. Аннан соң инде шушы үзара сөйләшүләрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең чишелеш юлларын эзли һәм таба иде.

– Әдәбият, язучылар турында барган сөйләшүләрдә Беренче Президент әледән-әле язучыларны профессиональ дәрәҗәдә әзерләү һәм университетта әдәбият факультеты ачу мәсьәләсен күтәрде. Мөнә шушы мәсьәләләрдә бүген нинди үзгәрешләр бар?

«Минтимер Шәймиевнең күңелена дә язучы орлыгы салынган, ул сүз кыйммәтен белә. Әгәр җитәкчелек эшенә кереп китмичә, журналистика яки язучылык һөнәрен сайлаган булса, аннан менә дигән язучы, романчы чыккан булыр иде. Чөнки ул дөньяны тыштан гына түгел, ә эчтән дә бик яхшы белә».

– Казан федераль университетында андый институт бар, әмма әлегә ул үзгәрешләр чорын кичерә. Бу, чыннан да, зур проблема. Әдәбият белгечләренең, журналистларның, язучыларның күбесе – татар филологиясе һәм тарихы факультетын тәмамлаган кешеләр. Аның башка юлдан китүе һәм бүгенге көндә үз куәтен югалтуы безне бик нык борчый. Минтимер ага да бу мәсьәлә белән бик нык кызыксына һәм аны көн үзәгендә тота. Әлеге хәлләрне, Казан федераль университетына барып, махсус өйрәнде. Әгәр без бу проблеманы хәл итмәсәк, милләтебезгә тагын да ныграк куркыныч янарга мөмкин. Бу мәсьәлә, дөрестән дә, иң авырткан җирләребезнең берсе.

– Мөмкин булса, Разил Исмәгыйлевич, Минтимер Шәриповичның музыкага, бүгенге эстрадага булган мөнәсәбәтен дә беләсе килә иде.

– Безнең «Җыен» фонды, татарның атаклы шәхесләренә багышлап, 50дән артык китап бастырды. Шулай бервакыт очрашкач, Минтимер әфәнде миңа: «Сез Сәйдәшне чыгардыгызмы әле?» – дип сорады. «Чыгарырга җыенабыз», – дидем. Шуннан соң ул: «Сәйдәш бит ул – татарның чын милли рухын бирә алган һәм моңын саклаган уникаль композитор», – диде.

Татар эстрадасы турында борчылып сөйләгән фикерләрен дә ишеткәнем бар. Мин белгәннән беренчесе – җыр текстларындагы мәгънәсез сүзләр, икенчесе – хәзерге көндә кайбер композиторлар язган музыканың милли моңы, милли нигезе булмау.

Татарстан Республикасының Шахмат федерациясе президенты Геннадий Захаров:

«Безнең дуслык сәясәттә һәм шахматта сыналды»

tatarstan.ru

– Минтимер белән без Минзәлә районында таныштык. Ул вакытта миңа – 25, аңа 23 яшь кенә иде әле. Мин Воровский совхозында баш инженер булып эшләгән чор бу. Минтимерне дә Мөслим районыннан соң безгә «Сельхозтехника» районара берләшмәсе җитәкчесе итеп билгеләделәр. Без ул вакытта югары омтылышлары булган алдынгы карашлы яшь егетләр идек. Актаныш, Зәй, Мөслим, Минзәлә, Сарман районнарында яңа, заманча алымнар кулланып эшләдек. Авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау буенча беренче урында бардык. Фонд биргән запчастьлардан тыш, өстәмә рәвештә үз тырышлыгыбыз белән, техника өчен кирәк-ярак таба идек. Актанышта агрономнар, механиклар, авыл советы рәисе белән килешенеп, төннәрен баржага бәрәңге төяи идек. Аны соңыннан Волгоградтагы трактор заводына җибәрдек. Шул рәвешле авыл хуҗалыгы техникасы өчен өстәмә детальләр кайтарттык. Соңыннан бер-бер артлы Казанга күчендек. Ләкин анда да бердәм идек, безнең дуслык шулай сәясәттә сыналды.

Минтимер бик сәләтле, акыллы кеше. Нинди генә аудитория алдында чыгыш ясамасын, барлык конфликтлы ситуацияләрне дә юмор белән чишә белә. Өстәлгә йодрык белән сукканчы, йомры сүзе көчлерәк тәэсир итә. Ул бик тәрбияле кеше, беркайчан да сүз көрәштерми. Җир кешесе. Кеше хәленә керә торган шәхес. Татарстанның Беренче Президенты буларак та бик хөрмәт итәм үзен. 1990 еллардагы авыр чорда алтын урталыкны таба алды. Татарларны, Татарстанның абруен күтәрү – аның иң зур казанышларының берсе. Татар халкы болай да бик тырыш, кунакчыл халыкларның берсе. Шәймиев исә милләтнең дәрәҗәсен тагын да күтәрүгә ирешә. Авыл хуҗалыгын үстерүгә дә зур өлеш кертте. Шуңа да республикада авыллар сакланып калды. Икмәк җитештерү буенча да без алдынгы рәтләрдә барабыз.

КПССның бер өлкә комитеты сәркатибе дә «Тузган торак» программасына алынмады. Минтимер беренче булды. Бауман урамының элеккеге хәлен генә искә төшерегез: җимерек өйләр, урамдагы бәдрәфләр... Ул кешеләрне яхшы шартларга күчерүгә ирешә. Башка төбәкләр аннан үрнәк алып кына бу эшкә тотынды.

Безнең иң яраткан шөгылебез – шахмат уйнау. Минзәләдән башланды ул чир. Илле елдан артык шимбә, якшәмбе көннәрендә шахмат уйныйбыз. Икебезнең дә көчләр бертигез. Уйнаган вакытта, яныбызга берәү дә килеп кысылып йөрмәве хәерлерәк. Кайвакыт бәхәсләшеп тә китәбез, яныбызга, сугыша башладылармы әллә дип, тән сакчыларына кадәр кергәне бар. Минтимер шахматта да, тормышта да бөтен әйберне ахырына кадәр җиткерә. Мин аның бу сыйфатына сокланам.

Минтимергә озын гомер, сәламәтлек, гаилә бәхете телим. Тормыш иптәше Сәкинә ханым, чын мәгънәсендә акыллы, матур кеше. Алар бер-берсен ихлас, самими мәхәббәт белән ярата. Улларын да намуслы кешеләр итеп тәрбияләргә ирештеләр.

Алисә САБИРОВА.

Җир кешесе

«Россия авыл хуҗалыгы үзәге»нең Татарстан филиалы җитәкчесе **Вагыйз МИНҺАҖЕВ** истәлекләре

– Вагыйз Василович, Минтимер Шәрипович белән беренче тапкыр күрешүегезне хәтердә яңартыйк әле.

– 1988 ел иде. Миңа ул вакытта 33 яшь. Минтимер Шәрипович – ТАССРның Министрлар Советы рәисе, мин Арча райкомының беренче секретаре булып эшлим. Моңарчы да ул алып барган җыелышларда катнашканым бар һәм аның яхшы нәтиҗәле эшне күрә, бәяли белгәненнән дә хәбәрдар идем. Бу – безнең зур уңышларга ирешкән еллар. Шуңа күрә аның безгә килүен куркып көтеп алдык дип әйтә алмыйм, тик, әлбәттә, күпмедер дулкынлану булгандыр.

– Гомер буе авыл хуҗалыгы тармагында эшләгән кеше буларак, Минтимер Шәриповичның бу өлкәдә кабул иткән иң мөһим карарлары дип кайсыларын атар идегез?

– Иң элек шунысын әйтәсем килә: ул авыл хуҗалыгын белә һәм ярата иде. Ашлама алырга акча булмаган бик тә авыр туксанынчы елларда ул «взаимозачет» белән ашлама алырга рөхсәт итте. Шулай итеп, без җирне җитәрлек тукландыра алдык. Россия буйлап мәҗбүри диярлек колхозларны тарата башлаган елларны да һәркайсыбыз хәтерлидер. Минтимер Шәрипович авыл хуҗалыгына таралырга ирек бирмәде, кайсы хуҗалык нинди идарә юлы белән яшәп, эшләп китә ала, шул юлны сайларга рөхсәт бирде. 2000 елларда запаслары бетеп аяктан егыла башлаган колхозларны холдингларга берләштерү дә ул чорда бердәнбер дөрес карар иде.

– Аны билгели торган төп сыйфат нинди дип саныйсыз?

– Иң күркәм сыйфатларының берсе – кешене сабыр итеп тыңлый белүе. Бу бик асыл сыйфат, башкаларны тыңлый, ишетә белүчеләр сирәк. Аннан соң гына ул үзенең фикерен белдерә һәм нәтиҗә ясый. Инде кешегә карата бер фикер туган икән, кемнеңдер сүзенә карап, аны үзгәртми һәм аңа булган ышанычын да югалтмый.

– Сез бик күп еллар идарәнең төрле баскычларында бергә эшләгәнсез, янәшә баргансыз. Эш дәверендә төрле вакытлар булгандыр, сезнең хәтердә усал һәм ихлас Минтимер Шәймиев ничек саклана?

– Ул бик ачуланганда да иң авыр сүзне әйтми кала һәм шул ук вакытта беркайчан да үз позициясен бирми торган җитәкче. Рус мәкалендәге кебек, чит кешене үз кырына кертми. Бу тормышта башкаларга зыян салырга теләүчеләр дә аз түгел. Минтимер Шәрипович андыйлар белән үчләшеп, ачу саклап йөрмәде. Бәлки аны бик яхшы ачуы белән чагыштырырга була торгандыр. Ашыгыч адымнар ясамас, бар да үз вакыты белән нәкъ ул әйткәнчә килеп чыга. Инде бик тә ачуы чыкса, русча сөйләшә торган иде.

Бик тә ихлас, күңеле ачылып киткән вакытны искә төшерсәк... Мин аңа тальян гармун бүләк иткән идем. Аның шул вакытта чын ихластан шатланганы, күңел кылларының кузгалганы хәтердә калган. «Гомер буе тальян турында хыялландым. Яшь вакытта әле акча җитмәде, әле икенче вакытта алырмын дип калдыра килдем. Менә кем кулыннан алырга насыйп булган икән», – дигән иде ул. Күңелендә тальян моңы йөрткән кеше – ул инде бөтенләй башка.

– Шәхсән сезнең өчен Минтимер Шәймиев кем ул һәм сез аңа нинди теләкләр җиткерергә теләр идегез?

– Ул минем тормышымда зур роль уйнаган кеше. Аның белән эшләгән еллар бик нәтиҗәле булды. Нинди генә зур эшләр башкарылмады... Иң беренче чиратта мин аңа, әлбәттә, сәламәтлек телим. Һәр нәрсәдә тәртип яратучы кеше буларак, Минтимер Шәрипович һәрвакыт сәламәт яшәү рәвеше алып барды, спорт белән әле дә шөгыльләнә. Бу аңа бүгенгәчә хезмәттә булырга ярдәм итә. Тормыш ничаклы гына катлаулы, четерекле димик, без барыбыз да җир кешеләре, табигатьнең бер өлеше, бер күзәнәге. Менә шуны аңлап, тоеп яшәүчеләр күпкә бәхетлерәк. Алар яңа яуган карны да күрә, тынлыкны да тыңлый белә. Минтимер Шәрипович әнә шундыйлардан. Әле күп еллар сау-сәламәт булып яшәргә, эшләргә насыйп булсын.

Чүпрәле районы, «Цильна» хуҗалыгы җитәкчесе **Борис ГАФУРОВ** истәлекләре

– Минтимер Шәймиев белән танышкан елларда Чүпрәле районының авыл хуҗалыгы буенча күрсәткечләре бик мактанырлык түгел иде. Безнең «Цильна» хуҗалыгында уңыш та яхшы, сөтне дә күп савабыз. Шуңа күрә мин аның күңеленә кереп калганмын, ахры. Районга килгән саен: «Нигә «Цильна» хуҗалыгында гына уңыш зур?» – дип шелтәли торган иде.

Тагын бер истәлекне күңелдә яңартып китәсе килә. Ялгышмасам, 1997 ел иде бугай. Минтимер Шәрипович: «Кайсы хуҗалык һәр сыердан еллык савымны 500 литрга арттырырга ирешә, шуңа КАМАЗ машинасы бирәм», – дип вәгъдә итте. Безнең «Цильна» хуҗалыгы еллык күрсәткечләр буенча, алдагы ел белән чагыштырганда, бер сыердан 1370 литрдан артыграк сөт савуга ирешә. Ике КАМАЗ була, өчкә җитмичә кала. Нишләргә? Ике машина сорап язган гаризама кул куйдырдым да, тәвәккәлләп, сүз башладым. «Минтимер Шәрипович, аз гына өченче КАМАЗны алмый калдык. Теге артык калган сөткә бер «КСК» бирмәссез микән?» – дип куркып кына, алдан әзерләп килгән икенче гаризамны сузам. Башта ул рәхәтләнеп көлде, аннары аңа кушылып мин дә көлдем. «КСК» сорап язган гаризамны сызып атты да «Полесья» бирергә дип язып куйды. Әле ул вакытта «Полесья» турында ишетеп кенә белә идек. Бу бит инде үзе бер аерым техника.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

Музейга әйләнгән туган йортына Минтимер Шәймиев ел саен кайта.

Бу йортта Шәймиевләр 1954 -1980 елларда гомер итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Президент туган авыл

Актаныш районы, Әнәк авылында 102 хуҗалык исәпләнә. Авыл мул, тату яши. Биек манаралары белән әллә кайдан ук күренеп торган мәчеттән ерак түгел Шәймиевләр нигезе урнашкан. Ул 2005 елдан Актанышның «Туган як» музее карамагында йорт-музей буларак эшли, Минтимер Шәймиевнең әтисе Шәрип ага исемен йөртә.

Эльвира МОЗАФФАР

Минтимер Шәймиев ел саен җәй көне балачак, яшьлек хатирәләрен саклаган туган йортына кайта. Туганнары белән бергә җыелышалар. Якыннары, әти- әнисе каберен зиярәт кылалар.

«Йорт музей итеп үзгәртелгән беренче елны әти-әнисеннән калган истәлекләрне карап йөргәндә, Минтимер Шәрипович күзләре яшьләнгән иде. Гадәттә, Шәймиевләр туганнары белән йортка килгәч, комачауламыйбыз, аларны борчымыйбыз, үзләрен генә калдырабыз», – ди музей-йортның директоры Гөлназ Гыйбадуллина.

ЭНЕМ ПРЕЗИДЕНТ БУЛГАЧ, КЕШЕГӘ СИЗДЕРМИ ГЕНӘ СӨЕНДЕМ

Шәрип ага белән Нәгыймә апа ун бала тәрбияләп үстерәләр. Кызганыч, бишесе сабый чакта вафат була. Бүген авылда Шәймиевләрнең бер туганы да юк. Авыл колхозында алдынгы механизатор, шофер булып эшләгән Хантимер абый да, РСФСРның атказанган укытучысы Мәрзия апа да, заманында Әнәктә хатын-кызларны хәреф танырга, язарга өйрәткән Дәргалия апа да бакыйлыкка күчкән. Минтимер Шәймиевнең бердәнбер исән апасы – Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре Мәдания ханым Чаллыда яши. Хәер, Әнәккә терәлеп үк торган Пучы авылында ике туган апасы Гөлбания апа бар.

– Минтимернең әтисе белән минем әни бертуган. Мин аннан ике яшькә олырак. Кечкенәдән үк энем белән бергә уйнап үстек. Әнәктә башлангыч мәктәптә бергә укыдык. Ул мине буй җиткәч тә гел саклады, яклады. Бер авыр сүз әйттермәде. Бүген дә хәлемне белеп тора. Кайткан саен хәер бирә, чәй эчми китми. Без исә аның кайтасын белгәч, ул яраткан тәбикмәкләрне пешереп куябыз. Зур коймакларны шулай атыйлар бездә. Әле менә 3 гыйнвар көнне мине туган көнем белән дә котлап шалтыратты. Сәкинәбез дә бик мөлаем, акыллы, уңган килен булды, Аллага шөкер, – ди Гөлбания Шәрәфиева. – Кечкенәдән үк яхшы укыды энем. Буш вакыты булуга, кулына китап ала иде. Менә мин начар укыдым. Ачлык еллары бит, дәрес, безнең гаилә ярыйсы яшәде анысы. Мәктәпкә ситсыдан тегелгән ике капчык алып бара идем: берсендә – дәреслекләр, икенчесендә – алабута ипие. Минем өчен дәрес эшләп биргәннәрне ипи белән сыйлыйм. И шул чакта Минтимер әрли иде мине. «Бания, син бит аңлы кеше, ник үзең эшләмисең?» – дия иде. Башлангычтан соң укуымны дәвам итмәдем. «Таш кисәргә кушсаң куш, тик укырга гына җибәрмә», – дигәнмен әнигә. Ник алай укыйсы килмәгән икән инде – белмим. Минтимер мәктәптән соң да укуын дәвам итте. Институтка керде. Шул чакта ук зур кеше булыр, ахры, энебез, дип уйлап куйган идек. Тырышлыгы аркасында гади генә авыл малаеннан Президент дәрәҗәсенә ирешә.

Сүз уңаеннан, Минтимер Шәймиев укыган Пучы авылындагы өч катлы таш мәктәп бүген дә саклана.

– Туганыгыз Президент булгач горурлангансыздыр? – дим Гөлбания апага.

– Эчтән генә горурландык, сиздерми генә сөендек. Кеше янында шапырынып йөрмәдек. Мактану кебек кабул итәрләр дип курыкканбыздыр инде. Хәзер Шәймиевне телевизордан күбрәк күрәбез. Ул экранга чыккан саен: «Нихәл, Шәйми?» – дип исәнләшеп куям. Менә уйлап торам, мин дә укыган булсам, аның янында бер начальник булган булыр идем әле, – дип көлә әңгәмәдәшем.

Бала чагында Минтимер Шәймиев әнисе оеткан катыкка Әнәк урманыннан җыелган җиләк болгатып ашарга яраткан. «Җиләк җыярга баргач, савыт тулмыйча, бер генә җиләкне дә авызга алмый идек», – дип искә ала ул үзе.

ИҢ ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ

Минтимер Шәймиевнең зур җитәкче буласын мәрхүмә укытучысы Хәдичә апа да сизенгән булган. Башлангыч сыйныфта укыганда, бер дәрестә ул укучыларга йолдыз рәсеме ясарга кушкан. Ул чакта кәгазьгә кытлык, газета кырыйларына гына язганнар. Минтимер, сыйныфташларыннан аермалы буларак, кәгазь битенең уртасына зур йолдыз ясап куйган. Янәшәсендә вак-вак кечкенәләре дә бар. Укытучысының гаҗәпләнүен күреп, саллы гына җавап та кайтарган: «Мин төнлә йоклый алмаганда, күккә карыйм. Анда йолдызлар күрәм, арасында иң зурысы башкалардан яктырак яна, рәсемдә шуны ясадым», – дигән ул. Хәдичә апа шул чакта ук моны бер билге дип кабул иткән, киләчәктә Шәймиевнең зур уңышларга ирешүенә юраган. Бу вакыйганы безгә музей җитәкчесе Гөлназ Гыйбадуллина тасвирлады. Барыбызга да таныш, шул ук вакытта ачылмаган яклары җитәрлек булган Шәймиев турында күп нәрсә сөйли ала ул. Нәселләрендә ир-атлар барысы да атлар ярата. Сабан туенда да чабышка еш чыккан Шәрип ага юртаклары. Шуңа күрә алар да кушаматлары «Чаптын» аларның.

Музейда иң кыйммәтле экспонат – Шәймиевләрнең нәсел шәҗәрәсе. Биредә 1725 елдан алып ун буынгача туганлык җепләре сурәтләнгән. 2017 елда музей эшчәнлеге тулысынча Минтимер Шәймиевнең юбилее белән бәйле булачак икән. Тиздән музей-йортны яңа экспонатлар белән тулыландырырга, нигезгә шәхси әйберләрен кайтарырга җыеналар.

Музей-йорттан Шәрип Шәймиев исемен йөрткән урам башлана. Рәйсә әби Мирзаһитова да шул урамда яши. 90 яшенә якынлашса да, хәтеренә сокланырлык.

– Энем Мирхәт белән Минтимер бер сыйныфта укыдылар. Кызганыч, энем гүр иясе инде. Мирхәткә Президент дәрәҗәсенә ирешкән классташын гел үрнәк итеп куя идем. Безнең авыл малайлары тәртипле, акыллы булды, шөкер. Минтимер белән Мирхәт тә чишмәдән көянтә белән су алып кайтучы хатын-кызны күрсәләр, шунда ук ярдәм итәләр иде. Сулы чиләкләрне өйгә кадәр үк кертеп куялар. Шәрип абый белән Нәгыймә апа да әйбәт булдылар. Күпләрне ачлыктан саклап калдылар. Элек-электән күршеләр булып, ярдәмләшеп яшәдек. Минтимернең кайтканын белсәк, без – авыл карчыклары – капка төбендәге эскәмиягә тезелешеп утырабыз. Ул килә, исәнләшә, хәерен бирә. Бу юлы кайткач та: «Нихәл, Рәйсә апа?» – дип килеп хәлемне белде. Карт кешенең күңеле булсын өчен шул да җитә инде, – ди Рәйсә әби.

Әнәк халкы авылдашлары Минтимер Шәймиевне хөрмәт белән каршы ала. Кайвакыт аның кайтканын сизми дә калалар, ә халык белән очрашасын белсәләр, алдан ук җыенып көтәләр икән. Урамнан барганда авылдашын күрсә, үзе дә сүз катмый калмый ди. Әнә шундый гади, кешелекле булганы өчен дә ихтирам итәдер аны халык.

«АВЫЛ МАЛАЕ БУЛУЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ»

– Минтимер Шәрипович, Президент вазифасында районнарга йөргәндә, авыл җирендә сез бөтенләй башка төрлегә әйләнә идегез. Тормышыгызда авыл нинди роль уйный?

– Дөрес, авылда үзгәрәм. Мин – авыл малае, шуның белән горурланам. Җирдә туып, шул тормышны күреп үсү, абзар исен иснәү, этләр, хайваннар арасында йөрү, дөресен әйткәндә, үзе бер могҗиза ул. Авыл җирендә мал арасында үстек без, шуңа күрә бер эт тәрбияләү турында гел хыялландым. Президент вазифалары моңа мөмкинлек бирмәде. Президентлыктан китәргә бер ел кала, алдан ук эт баласы алып куйдым. Исеме Тукай шигыреннән алынды – Маһмай. Без аның белән бик дус.

Авыл – туып-үскән җирем. Безнең характерны авыл формалаштыра. Кешеләрне яратырга өйрәтә ул. Авылда тууның гаҗәеп бер өстенлеге бар: демократик җәмгыятьтә яшисең. Тулы хәбәрдарлык: беркемнең бернинди сере юк, бар да күз алдында, бар да ачык.

– Әнәккә еш кайтасызмы?

– Кызганыч, еш кайта алмыйм. Елга бер, күп дигәндә, ике тапкыр. Минем тормыштагы бердәнбер үкенечем: әнкәй мәрхүмә исән чагында ешрак кайтып булмады. Әткәй үзе дә гомер буе җитәкче урыннарда эшләгәч, аңлый иде, тик әнкәйгә игътибар җитмәде. Үзе безгә кунакка килгәли иде. Мин эштән кайткач, кичке аштан соң утырабыз икәү диванда. Әнкәй сөйли дә сөйли… Аның минем белән сөйләшәсе килә. Ә мин йокыга китәм… «Сөйли-сөйли дә син җавап бирмәгәч, берәр каты гына сүз әйтеп торып китә иде», – ди Сәкинә.

Әнкәйләргә алар исән чакта игътибар күрсәтергә кирәк. Мин һәркемгә һәрчак әйтә киләм: «Әниең исән чакта ешрак кайт», – дим.

Минтимер Шәймиевнең «Шәһри Казан» газетасына биргән әңгәмәсеннән, 2015 ел, июнь.

«Абый миңа үрнәк булды»

Мәдәния ИЛЬЯСОВА, Минтимер Шәймиевнең бертуган сеңлесе:

– Сугышка кадәр туган авыл балаларын ачлык, ялангачлык үстерде. Аңа карамастан, без тырыш, эшчән булып үстек. Үзебезне белгәннән бирле һәрчак эштә булдык. Өйдә һәр баланың үз вазифасы бар иде. Олы абыебыз Хантимер маллар янында булса, Минтимер абыем әтигә хуҗалык эшләрендә булышты. Бакчада чүп утаганда һәр кешегә күпме утыйсын бүлеп бирә иде. Үзенең җирен тиз-тиз генә утап бетерә дә уйнарга чыгып китә. Без бигрәк тә «Городки» уйнарга яраттык. «Шәпи» уйнадык. Минтимер абыйның яраткан уены да шул иде. Тупны сыер ябагасыннан үзебез ясадык.

Минтимер абый бәләкәйдән ат җикте. Аның белән кечкә таба Урта сазлыкка печән чабарга бара идек. Бервакыт, борчак өлгергән чак булгандыр инде, кырга торналар төшкән булган. Минем аларны беренче күрүем, озын муенлы торналарны күреп куркып калганмын. «Абый, Мулла басуында җеннәр йөри, әйдә тизрәк кайтыйк», – дим. Ул чалгысына таянды да кычкырып көлде. Шунда таба йөгереп китте дә торналар һавага күтәрелде.

Укуда да сынатмадык. Мин абыйдан ике яшь ярымга кечерәк. Ул –тугызынчы, мин – унынчы бала. Абый укырга яратты, аңа карап мин дә тырышып укыдым. Башлангыч сыйныфта Хәдичә апа укытты. Беренче белән өченче сыйныфлар бергә иде. Өченче сыйныфка математикадан бирем биреп, без беренчеләрне хәрефләр танырга өйрәтә. Абый, биремне тиз генә чишеп, такта янына укытучы урынына чыга да укыта башлый. Хәдичә апаны бик яратты. Мәктәптә укыганда Габдулла Тукайның «Бала белән күбәләк» шигырен сөйләгәнебез истә. Әнкәйнең бәйрәмнәргә генә кия торган ефәк шәлен иңемә салып, мин Күбәләк булып уйныйм. Абый биергә дә яратты. Яңа елга чыршы бизәргә дә уенчыкларны үзебез ясый идек. Чыршы бәйрәмнәрендә абый аю була иде. Әтинең кулдан тегелгән тунын әйләндереп киеп, чыршы тирәсендә йөргәне истә.

Абый буларак, ул бөтен яктан миңа үрнәк булды. Кирәк урында җитди дә, кирәк урында шаян да була белде.

Классташ

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ, язучы, шагыйрь, танылган бакчачы, академик:

– Без Минтимер Шәймиев белән Актаныш районының Пучы мәктәбендә бергә укыдык. Икебез дә бер елгы. Сигезенче сыйныфны бергә укысак, югарырак классларда бүлендек. Ул чакта «а», «б», «в», «г» сыйныфлары да бар иде. Минтимер Шәймиевнең мәктәп елларын бары яхшы яктан гына искә алырга була. Үрнәк, тырыш, актив укучы булды. «Бишле» билгеләренә генә укыды. Укытучыларыбыз да яхшы иде. Төпле белем бирделәр. Немец теле укытучысының өстәл кага-кага укытканын бүген дә хәтерлим.

Ярдәм сорап килсәң дә кире бормый иде Минтимер. Кешелекле булуы белән дә истә калган. Берсендә, Пучы мәктәбенә төрле авыллардан килеп укый торган малайлар белән өйгә кайтканда таеп китеп, җайсыз егылдым. Шул чак классташым Минтимер тиз генә килеп җитеп, миңа торырга булышкан иде. Чыгарылыш кичәсен дә бергә үткәрдек. Мәктәпне тәмамлаганга 50 ел булу уңаеннан оештырылган чарага гына кайта алмады. Аның бертуганы Мәрзия гел шалтыратып хәлемне белә иде. Әтиләре Шәрип ага белән дә аралашканыбыз булды. Минтимер Шәймиев – минем өчен якташым, сыйныфташым, чорыбызның күренекле кешесе, үрнәк. Без аның белән горурланабыз.

«Авыр чакта ярдәм итте»

Актаныште Минтимер Шәймиев белән бер чорда эшләгән Баязит Мөхәммәтов яши. Ул – районның ихтирамга лаек кешесе. Баязит әфәнде 18 ел Актаныш халык депутатларының район советы башкарма комитеты рәисе булып торган. Озак еллар районда 80нче һөнәр училищесын җитәкләгән. Күпләр яратып, хөрмәт итеп, аны «Б.Ш.»дип тә йөртә. «Күрәсең, бу кушамат «бөек шәхес» дигәнне аңлатадыр», – ди уенын-чынын бергә кушып Баязит абый үзе. Ул «ШК»га Минтимер Шәймиев турында хатирәләрен сөйләде.

– Мин Минтимер Шәймиевне 60нчы еллардан бирле якыннан беләм. Аның җитәкчелегендә күп еллар Актаныш районында партия-совет органнарында эшләргә дә туры килде. Ул минем тыйнак хезмәтемне күрде. «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены һәм аның кулы белән имзаланган өч мактау грамотасы алу, башка бүләкләр, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исемен йөртү – ул биргән бәя турында сөйли. Моның өчен бик рәхмәтлемен.

Минтимер Шәймиев эшкә бик җаваплы караву, мәсьәләне уйлап хәл итүе, киң эрудицияле, ярдәмчел, кешелекле булуы белән тирән эз калдырды. Республикада социаль-икътисади үсешне тәэмин итү, халык мәнфәгатьләрен кайгырту, тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту буенча куйган хезмәтләре, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, башка тармакларның үсеше, газлаштыру, тузган торакны бетерү программалары үзләре генә дә зур казаныш булып тора. Бик катлаулы шартларда республиканың суверенитеты мәсьәләсен хәл иткәндә аның акыллы сәясәт алып баруы төрле яктан отышлы булды. Минтимер Шәрипович республиканың мелиорация һәм су хуҗалыгы министры булып эшләгән чорда, яңа Актанышны төзегән елларда халыкны су белән тәэмин итү мәсьәләсен министрлык үз карамагына алды.

Түбән Кама ГЭСы төзелгәндә, безнең район су басу зонасына эләкте. Проект нигезендә районның 30 мең гектарга якын мәйданны билгән авыл хуҗалыгы җирләрәнә су басу куркынычы янады. СССР җитәкчелегеннән «су басасы урыннарда бернинди төзелеш эше алып бармаска» дигән катгый күрсәтмә бирелде. Нәтиҗәдә икмәк кабул итү пункты, нефть базасы кебек авыл хуҗалыгы өчен кирәкле оешмалар авыр хәлдә калды. Яңаны төзергә ярамый, ремонт өчен дә күпләп акча тоту мөмкинлеге булмагач, аларның материаль-техник базасы начарланды. Төяү, бушату, киптерү механизмнары еш ватыла башлады. Ул елларда игеннәр гөрләп үсте, уңыш югары иде. Урып- җыю эшләрен генә тоташ яуган яңгыр астында башкарырга туры килде. Амбарларда юеш икмәк тау булып өелде. Төтенләп яна ук башлады. Нишләргә? Минтимер Шәриповичка шалтыратып, авыр хәлне аңлаттым. Ул икенче көнне үк килеп җитте. Хәлне үз күзләре белән күреп, исе китте. «Монда ашыгыч рәвештә элеватор төзергә кирәк», – диде. СССР Хәзерләүләр министрлыгы яңа элеватор төзергә каршы булса да, икмәкне Башкортстан Республикасының Илеш районындагы элеваторга тапшырырга кушса да, Минтимер Шәрипович үз сүзендә нык торып, куйган максатына ирешә. Чиләбе өлкәсеннән «Южуралэлеваторстрой» тресты эшчеләрен китертеп, 1985-89 елларда кыска гына вакыт эчендә 35 мең тонна сыешлы элеватор төзетте. Төзелеш барышын үзе контрольдә тотты. Хәзер икмәкне кая куярга, ничек сакларга дигән кайгы юк. Анда бүген он да, ярма да, комбикорма да ясыйлар. Территориягә барып керсәң, чәчәккә күмелгән ишегалдының чагасы да килми. Бу игелекле эшләре өчен район халкы Минтимер Шәймиевне олы ихтирам, рәхмәт сүзләре белән искә ала. Аның җитәкчелегендә республикада башкарылган эшләрне бер язмада гына әйтеп бетерү мөмкин түгел. Ул кешелеклелек сыйфатлары, гамәлләре белән республиканың данын, үзенең исемен бөтен дөньяга танытты, халыкның хөрмәтен, ихтирамын яулады. Аңа киләчәктә дә исән-сау булып, тормыш иптәше Сәкинә Шакировна белән бергә, балаларының, оныкларының, дусларының, хезмәттәшләренең, гомумән республика халкының, ил җитәкчелегенең күңел җылысын тоеп яшәүләрен телим.

КОМСОМОЛ ТУЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

1965 елның 18 декабрендә Минзәлә районының Бикбул авылында булган комсомол туе турында ул көннәрдә ишетмәгән кеше калмагандыр. Бөтен авыл гөж килгән ул вакытта. Бер көндә дүрт пар бер табын артында туй үткәргән. Дүрт пар да тумышлары белән шул авылдан, бер колхозда эшләгәннәр. «Безнеке кебек туй беркемдә дә булмагандыр, туебызда хәтта Шәймиев тә бар иде», – дип искә ала әлеге парлар 51 ел элек булган туй мәҗлесләрен.

Гөлнәзирә белән Мирхәт Бәхтиевләр, Хәят белән Касыйм Басыйровлар, Кәнҗимә белән Зәфәр Нуриевлар, Мөнҗия белән Фәүзетдин Нуриевлар туй көннәрен махсус алдан сөйләшеп билгеләмәгән дә булган. Очраклы гына туры килде ул, ди алар. Моны белеп алгач, колхоз җитәкчелеге дүрт туйны бер зур мәҗлес итеп оештырырга була.

– Туебыз клубта узды. Моңа кадәр андый хәлнең булганы да юк иде. Барыбыз да туй күлмәкләреннән идек. Башка кияргә туй фаталарын Минзәләдән алып килделәр. Фата да түгел, калфаклар иде ул. Һәр пар кунак итеп алтмышар кеше чакырды. Районнан дәрәҗәле кунаклар да бар иде. КПСС район комитеты секретаре Гөлсабира Хәкимова, ул вакытта «Сельхозтехника» берләшмәсе җитәкчесе булган Минтимер Шәймиев тә килде. Район кунаклары безгә үзләренең теләкләрен җиткереп, чәй сервизы бүләк итте, – дип, Гөлнәзирә апа әле дә кадерләп саклаган дүрт чынаягын алып күрсәтә.

Кәнҗимә апаның хәтерендә колхоз исеменнән ике тукмаклы күкеле сәгать бүләк итүләре истә калган. Ул бүләккә без бик сөенгән идек, ди ул.

Табын әзерләүне колхоз үз өстенә ала. Яшьләргә үзләре белән ипи һәм эчемлекләр алып килергә кушалар.

– Ни җитте генә туй булмады ул, хәзерге кебек, официантларга хәтле булды. Без әзергә бәзер булып утырдык дип әйтергә дә була, – дип сөйли Кәнҗимә апа.

Алай гына да түгел, әлеге комсомол туен кино итеп төшереп телевизордан да күрсәткәннәр.

– Өч көн буена фотога төшереп аптыратып бетерделәр. Җигүле атларга утырып, баяннар уйнап, авыл урамнары буйлап узабыз. Икенче көнгә дә шул ук хәл кабатлана. Читтән, Казаннан килүчеләр булгандыр инде ул, безне фотога төшереп җәфалап бетерделәр. Ул фотолар клубта да бик озак эленеп тордылар. Мондый туй безгә кадәр дә, бездән соң да булмады, – ди Хәят апа.

Кәнҗимә апаның фотоальбомында яшьләргә бүләк итеп бирелгән открытка да саклана. Аның урта битенә: «Уртак мәхәббәткә корылган семья тормышы зур бәхет бирә ала. Н.Крупская», – дип язылган.

– Шөкер, мәхәббәтләребезгә тугры калдык, матур итеп яшәргә тырыштык, әле бүген дә яңа гына өйләнешкән парлар кебек яшибез, – дип елмая әлеге парлар.

Кызганыч, Хәят апаның ире Касыйм абый, Мөнҗия апа белән Фәүзетдин абый Нуриевлар – бүген гүр ияләре.

Гомерләре буе колхозда эшләп, бүген инде лаеклы ялда булган, матур гомер кичереп, балалар үстергән бу парлар бүген оныкларына сөенеп туя алмый. Кайберләренең оныклары да башлы-күзле булган инде.

Шәймиев абый

Рәис ӘХМӘТОВ,
Минзәләдә («Сельхозтехника» берләшмәсендә инженер булып эшләгән):

– Мин дә, аның кебек үк, Авыл хуҗалыгы институтының инженерлар әзерләү факультетында укыдым. 1964 елны, институтны тәмамлагач, юллама белән үз районыма, «Сельхозтехника»га эшкә җибәрделәр. Ул вакытта җитәкчебез Минтимер Шәймиев иде. Башта гади эшче, инженер-технолог булдым, аннары баш инженер итеп куйдылар. Бу барысы да ике ай эчендә булды. Минтимер Шәрипович инженер вазифасын башта ук бирмәде, сынап карады. Ул башта кешене нәрсәгә сәләтле булуын сүз белән дә, эш белән дә тикшерә иде. Беркөнне үз янына чакырды да, баш бухгалтер өенең түбәсен яба, ул дүрт кыеклы чатыр формасындагы шатрун түбә булачак, ничек уйлыйсың, аңа ничә табак калай кирәк булачак, дип сорый. Өй түбәсенең, калайларның размерларын әйтеп, икенче көнгә уйлап килергә кушты. Ә мин аңа җавапны ун минуттан әйтеп бирдем. Шунда алдында яткан кәгазьгә карады да елмаеп, әллә мин, әллә син бер табакка гына ялгыштык, диде. Ә икенче бервакытны миннән, өйгә куела торган электр исәпләгечен ничә үткәргеч тоташтырыла, дип сорый. Икаү, мин әйтәм. Өч фазалы булса, дип, янә сорау бирә. Алай булганда – сигез, дим. Синең бу белемнерең Тукай исемендәге колхозга электр үткәргәндә кирәге чыгачак дип, мине шунда җибәрде. Без анда ике атна эшләдек, эшебезне Минтимер Шәрипович үзе дә килеп карады. Канәгать калды. Шулай итеп, сынауларны яхшы үттем. Миңа ныклап ышангач кына, инженер итеп куйды. Оста җитәкче шундый була да инде. Сәләтең, белемең бар икән, рәхим итеп эшлә. Булдыксыз булсаң, аяк астында чуалып йөрмә. Үзе дә тырыш кеше булды. 1966 елда районыбыз социалистик ярышта беренче урынны алды.

29 яшендә Шәймиевкә Ленин ордены бирделәр. Шул яшьтә шундый зур бүләккә лаек булу өчен күпме тырышлык куярга кирәк. Хәтерлим: ул җитәкчелек иткәндә, берләшмәдә эчүчелеккә каршы көрәш алып барылды. Салган кешеләрне үткәрү пунктыннан кертмиләр дә иде. Шундый приказ да бар иде. Мастерской буйлап үзе карап йөри, салган кешене күрсә, профкомны да, башка җаваплы кешеләрне дә чакыртып, чара күрергә куша. Үзе тавыш та күтәреп кычкырмый, тыныч кына әрли, ә гаепле кеше, оялуыннан, кып-кызыл булып чыга, уңайсызлана. Ә менә хезмәт хакын кисеп калып, аның гаиләсенә авырлык китермәскә тырышты.

Муллахмәт КӘРИМОВ,
Минзәлә районының Бикбул авылы («Сельхозтехника» берләшмәсендә шофер булып эшләгән):

– Без аңа Минтимер Шәрипович дип эндәшми идек. Авыл кешесе абый, апа дип сөйләшә бит инде. Нишләптер Минтимер абый дип түгел, Шәймиев абый дип сөйләшкәнне хәтерлим. Мин «Сельхозтехника»да шофер булып эшләдем. Иртәнге биштә үк эшкә килеп утырам. Шәймиев абый да шул вакытка ук килә. Беркөнне безгә яңа машина кайтты. Аны механик үзенең туган тиешле кешесенә бирде, ә миңа аның иске машинасы каласы булды. Ул вакытта фанер кабиналы машиналарда йөри идек. Яңа машинага утырасым килгәндер инде, моңа ачуым килеп, аның янына кердем дә, Шәймиев абый, мин эштән китәм, дип ярып салдым. Ник китәсең, ди. Хәлне аңлатып биргәч, механикны чакыртып, яңа машинаны миңа бирдертте. Ул бик ярдәмчел кеше. Утын яки печән, башка кирәкле нәрсә сорап керсәң, беркайчан да кире борып чыгармый иде. Гадел, туры сүзле булды. Безнең янда үзен гади тотты, син нәчәлник, син гади эшче дип бүлеп карамады.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

– Әле күптән түгел генә газетабызда «Шәймиевне юксынабыз» дигән бер хат басылган иде. Минзәләдән бер ханым язган. 1962-67 елларда Шәймиев «Сельхозтехника»ны җитәкләгән чорда игенне вакытында чәчтеләр, урдылар, бөтен техника һәрвакыт төзек торды, гектардан 35-40 центнер уңыш ала идек. Без аны бөтен район белән юксынабыз, безгә ешрак килсен иде, дигән.

– Минзәлә кешеләренең сагынуына килгәндә шул: мин анда эшләгәндә эш урынындагы эчкечелекне бетергән идем. Шуңа сагыналардыр. Мөслимдә баш инженер булып эшләгән җиремнән Минзәләгә күчкәч, шаккаттым. Эшкә салып килеп, шул хәлдә көн уздырып йөрүчеләр бихисап. Мин моңа түзеп тора алмадым. Ныклап тотындым, нык шөгыльләндем. Көрәш ысулларым законлымы, законсызмы дип тормадым. Әгәр эш урынына исерек килеш килү факты булса, эшне башлатмыйм, «Сельхозтехника»га урамнан ук кертмим. Бераү эчеп килсә, бөтен эшче эш башлый алмый тора. Иптәшләр суды оешты. Букреев дигән бик абруйлы, алтын куллы тимерче – баш судья иде. Ул хөкем итә, мин ахырдан нәтиҗә чыгарам. Менә шулай эшчеләр көн дә-көн дә бер-берсен чыбыркылый торгач, биш ел эчендә тәртип урнашты.

Минзәләдән киткәндә ул эшчеләрнең хатыннары мине елый-елый озатты. Аларның бөтен серләре миндә иде: балалары ничек укый, нинди авырлыклары бар, ире кичә сәгать ничәдә кайтып кергән, кемгә утын илткән дә эчеп кайткан... Хатын-кызга бит иренең эчеписереп төнге бердә кайтып керүе кирәкми. Иртән тагын эшкә чыгып китәсе бит. Бу яктан без теләктәшләр идек. Кыскасы, мин һәрнәрсәдән хәбәрдар идем.

Минтимер Шәймиевнең «Татарстан яшьләре» газетасына биргән әңгәмәсеннән, 2007 ел, сентябрь.

«Ул гыйлемле дә, хикмәтле дә»

Госман хәзрәт ИСХАКЫЙ, *1998-2011 елларда Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти:*

– Минтимер Шәрипович белән миңа гомрә хаҗын кылырга насыйп булды. Без Согуд Гарәбстанына ислам конференциясе оешмасына бардык. Сәфәребез ахырында кече хаҗны кылдык. Анда республикадан шактый кешеләр бар иде. Аңлавымча, Минтимер Шәймиевнең Кәгъбәтулланы, «әл-Хәрам» мәчетен күрү теләге зур иде. Безгә бик зур хөрмәт күрсәтелде. Шунда Президентның дәрәҗәсе югары булуын күрдем, хәтта ул мондый игътибардан кыенсынган да кебек булды. Госел коендык, ихрам халәтенә кердек. Габдрахман исемле шәех безне озатып йөрде. Ул кулларын күтәреп дога кыла, без аның артыннан кабатларга тиеш. Минтимер Шәриповичка доганың сүзләре аңлашылсын өчен, мин гарәпчәдән татарчага тәрҗемә итеп бардым. Шәех бер җөмләне әйтә дә, мин аның татарчасын әйтәм. Шунда онытылып китеп, бер җөмләне тәрҗемә итмәгәнмен. Минтимер Шәрипович, хәзрәт, без аңламый калдык бит, татарчасы ничек була, дип куйды. Менә шундый нечкә эшләрдә дә ул төгәллек таләп итте. Аңламый калган нәрсәне шунда ук ачыкларга тырыша торган гадәте бар иде. Кәгъбәтуллаһ тирәли җиде тапкыр тәваф кылдык, намаз укыдык, дога кылдык. Минтимер Шәрипович моңардан бик тәэсирләнгән иде. Китәр алдыннан, никадәр генә ашыксак та, хәзрәт, бераз гына басып торыйк әле, ди. Кәгъбәтуллага борылып, карагыз мондагы энергетиканы, дип сокланып, тагын дога кылыйк әле, дип әйтеп куйды. Үзебез, халкыбыз, динебез, республикабыз өчен дога кылдык.

Минтимер Шәймиев белән мин унөч елдан артык эшләдем. Ул – әдәпле, зыялы, хикмәтле шәхес. Барысын да тирәннән уйлап эш итә торган кеше. 90нчы елларда, дин яңа гына күтәрелеп киткәндә, ниндидер бер катлаулы мәсьәлә килеп туганда, Җәлил хәзрәт Фазлыевны чакырып киңәшләшә, Тәлгать хәзрәтне, аннары мине чакыра, Равил хәзрәт белән очраша. Барысын да тыңлаганнан соң, бөтенебезне дә ризалата торган фикерен әйтеп куя иде, без шакката идек. Ничек моңарчы без моны чишә алмадык, шуңа башыбыз җитмәде, дия идек. Беркайчан да кискен карарлар кабул итмәде, ул халыкка ничек тәэсир итәр, нәтиҗәсе ничек булыр дип уйлады. Унөч ел дәверендә бик күп мәчетләр, мәдрәсәләр, Россия ислам институты ачылды. Минтимер Шәрипович институтка бина бирде. Аның белән эшләгән елларым бик нәтиҗәле булды. Кешедә гыйлем белән хикмәт бергә булырга тиеш, Минтимер Шәриповичта да ул шулай иде. Гыйлем генә булып, хикмәтең булмаса яки киресенчә, хикмәтең булып, гыйлемең җитәрлек түгел икән, бер канатлы кош кебек – оча алмыйсың. Ул үзе дә очты, безне дә үз артыннан очырды. Ватаныбыз, динебез өчен бик күп файдалы эшләр эшләде.

– Әтиегез Шәрип абый – гомер буе коммунист булган һәм бер тапкыр да мәчеткә аяк басмаган кеше. Ә сез «Кол Шәриф» мәчетен төзеттегез, изге урыннар – Болгар, Зөяне төзекләндерәсез. Бу эшләргә алынганда, күңелегездә ниндидер каршылыклар булмадымы?

